**МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** г. Казань **БОЕРЫК**

№724-п от 09.12.2013г.

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга бәйле дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын раслау турында» 2013 елның 09 декабрендәге 724-п номерлы боерыгы

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль законның 5 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт функцияләрен үтәү буенча административ регламентларны һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау турында» 2011 елның 16 маендагы 373 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга бәйле дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын (алга таба – административ регламент) расларга.

2. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Административ регламент раслау турында» 2010 елның 24 мартындагы 213 номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге административ регламент үтәлешен контрольдә тотуны Дәүләт экологик күзәтчелек инспекциясе җитәкчесенә (Т.Н.Гыйльметдинов) йөкләргә.

4. Хокукый тәэмин итү бүлегенә (В.А. Тронин) әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында теркәлүен тәэмин итәргә.

5. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.Х.Низамовка йөкләргә.

Министр А.Г. Сидоров

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыруга бәйле дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты (ТР Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 9 декабрендәге 724-п номерлы боерыгы белән расланды)

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Административ регламент (алга таба – Регламент) Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының (алга таба – ТР ЭТРМ) юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата «төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру» дәүләт функциясен (алга таба – дәүләт функциясе, калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге, дәүләт күзәтчелеге) үтәгәндә гамәл кылу чорларын һәм тәртибен билгели.

Калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеге төбәк дәүләт экология күзәтчелегенең бер өлеше булып тора, аны үткәрү тәртибе Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2013 елның 9 декабрендәге 721-п номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентында (алга таба – Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты) билгеләнгән.

1.2. ТР ЭТРМ – дәүләт функциясен үтәүче булып тора.

Дәүләт функциясен турыдан-туры башкаручы булып ТР ЭТРМ Дәүләт экологик күзәтчелек инспекциясе һәм ТР ЭТРМ территориаль идарәләре тора.

Дәүләт функциясе турыдан-туры ТР ЭТРМ вазыйфаи затлары – Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры (алга таба – министр), Татарстан Республикасы экология һәм табигать ресурслары министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары), (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 елның 21 сентябрендәге 784 номерлы карары нигезендә билгеләнгән) ТР ЭТРМ министры урынбасары (алга таба – министр урынбасары) боерыгы белән вәкаләт бирелгән табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары (алга таба – вазыйфаи затлар) тарафыннан үтәлә.

Дәүләт функциясен үтәгәндә вазыйфаи затлар прокуратура органнары, Россия Федерациясе законнары нигезендә илкүләм аккредитация системасында аккредитацияләнгән эксперт оешмалары (алга таба – эксперт оешмалары), дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар белән хезмәттәшлек итә.

1.3. Дәүләт функциясе түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе (Российская газета, 1993, 25 декабрь, № 237, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы 2001 елның 30 декабрендәге 195-ФЗ (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №1, 1 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Җир кодексы 2001 елның 25 октябрендәге 136-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 29.10.2001, № 44, 4147 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Су кодексы 2006 елның 3 июнендәге 74-ФЗ (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 23, 2381 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы,  №26, 3009 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2002, №2, 133 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе законнар җыентыгы, 2008, №52, 6249 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 19, 2060 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль закон (Российская газета, 2011, 6 май, №97, Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 19, 2716 ст., Парламентская газета, 2011, 13 май, № 23, кертелгән үзгәрешләрее исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Калдыкларны транспорт белән чик аша урнаштыру турында» 2003 елның 17 июлендәге 442 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2003, № 29, 3012 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәр итү тәртибе турында» 2009 елның 16 июлендәге 584 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2009, №30, 3823 статья, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Лицензиянең үрнәк рәвешен раслау турында» 2011 елның 6 октябрендәге 826 номерлы карары (Российская газета, 2011, 19 октябрь, N 234, Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 42, 5924 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «I-IV хәтәрлек классларына караган калдыкларны паспортлаштыру тәртибе турында» 2013 елның 16 августындагы 712 номерлы карары (алга таба – 712 номерлы РФ Хөкүмәте карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2013, № 34, 4443 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Федераль дәүләт экология күзәтчелеге турында» 2014 елның 8 маендагы 426 номерлы карары («Россия Федерациясе законнары җыентыгы», 19.05.2014, № 20, 2535 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «I-IV хәтәрлек классларына караган калдыкларны җыю, транспорт белән күчерү, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү турында» 2015 елның 3 октябрендәге 1062 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 03 октябрендәге 1062 номерлы карары)(Россия Федерациясе законнары җыентыгы), 2015, № 41, 5670 ст.)

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең хәтәр калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, транспортлау, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын раслау турында» 2007 елның 10 декабрендәге 848 номерлы боерыгы (алга таба – 2007 елның 10 декабрендәге 848 номерлы Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2008, №15);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контрольлегенен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольлекне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшмәкәрләрнең хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру турында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (Российская газета, № 85, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның «Илкүләм стандарт раслау турында» 2009 елның 15 декабрендәге 1091-ст номерлы боерыгы (алга таба – 1091-ст номерлы боерык) (текст рәсми рәвештә басылып чыкмаган);

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең «I-IV класслы куркыныч калдыкларны паспортлаштыру эшен оештыру турында» 2010 елның 24 декабрендәге 441 номерлы боерыгы (алга таба – табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 441 номерлы боерыгы) (текст рәсми рәвештә басылып чыкмаган, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Федераль дәүләт статистикасы хезмәтенең «Федераль дәүләт статистикасы хезмәте тарафыннан җитештерү һәм куллану калдыкларын күзәтү өчен статистик инструментарийны раслау турында» 2011 елның 28 гыйнварындагы 17 номерлы боерыгы (Вопросы статистики, 2011, N 5, формаларны теркәмичә генә басылып чыккан);

Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең «Калдыкларның федераль классификацион каталогын раслау турында» 2014 елның 18 июлендәге 445 номерлы боерыгы (алга таба – 445 номерлы Росприроднадзор

боерыгы) (Российская газета, 2014, 19 сентябрь, № 214, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының «Куркыныч калдыкларны әйләнә-тирә табигать мохите өчен куркынычлылык классына кертү критерийларын раслау турында» 2001 елның 15 июнендәге 511 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Табигать министрлыгының 511 номерлы боерыгы) (Природно-ресурсные ведомости, 2001, № 45);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының «Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» 2010 елның 25 февралендәге 50 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Табигать министрлыгының 2010 елның 25 февралендәге 50 номерлы боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2010, № 17, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Калдыклар белән эш итү өлкәсендә исәпкә алу тәртибен раслау турында» 2011 елның 1 сентябрендәге 721 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Табигать министрлыгының 2011 елның 1 сентябрендәге 721 номерлы боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2011, № 44, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә хуҗалык һәм башка эшчәнлек алып барганда әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты ясый торган һәм федераль дәүләт экологик күзәтчелегенә караган объектлар исемлеген раслау турында» 2011 елның 8 сентябрендәге № боерыгы (Государственное управление ресурсами, 2013, махсус чыгарылыш, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары министрлыгының «Калдыкларның дәүләт кадастрын алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елның 30 сентябрендәге 792 номерлы боерыгы (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2011, № 50);

Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2014 елның 5 августындагы 349 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Табигать министрлыгының 349 номерлы боерыгы) (Россия газетасы, 2015, 30 гыйнвар, № 18/1, махсус чыгарылыш);

Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының «Санитар кагыйдәләр – СП 1.1.1058-01 гамәлгә кертү хакында» 2001 елның 13 июлендәге 18 номерлы боерыгы (алга таба – СП 1.1058-01)(Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене 2001, № 45, Российская газета, 2001, 13 ноябрь, № 222, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының «СанПиН 2.1.7.1322-03 санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне һәм нормативларны гамәлгә кертү турында» 2003 елның 30 апрелендәге 80 номерлы боерыгы» (алга таба – СанПин 2.1.7.1322-03

«Җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыруга һәм зарарсызландыруга карата гигиена таләпләре») (Российская газета, 2003, 28 май, № 100);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы мәсьәләләре» 2005 елның 06 июлендәге 325 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы», 27.07.2005, № 28, 0654 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлекләрен раслау турында» 2011 елның 21 сентябрендәге 784 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 26.10.2011, № 40, 2038 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентын раслау турында» 2013 елның 9 декабрендәге 721-п номерлы боерыгы («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 06.05.2014, № 33-34, 1040 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).

1.4. Дәүләт күзәтчелеге, оештыру-хокукый формасына һәм милек формасына бәйсез рәвештә, төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә караган хуҗалык һәм башка эшчәнлек объектларында гамәлгә ашырыла.

Дәүләт күзәтчелеге предметы булып юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан Россия Федерациясе халыкара шартнамәләре, «Житештерү калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы, «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законнар, башка федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителә торган, калдыклар белән эш итү өлкәсендә, әйләнә-тирә мохитне саклау, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыру өчен түләүне тикшерүдә тоту өлкәсендә Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары нигезендә билгеләнгән таләпләр (алга таба – зарури таләпләр) үтәлеше тора.

1.5. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда вазыйфаи затларның хокуклары һәм бурычлары.

1.5.1. ТР ЭТБМ табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары булган вазыйфаи затлары Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә хокуклы:

1) дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан һәм гражданнардан тикшерү барышында кирәкле мәгълүмат һәм документларны соратып алырга һәм алырга;

2) хезмәт таныклыгын һәм министрның (министр урынбасарының) тикшерү билгеләү турында боерыгы (күрсәтмәсе) күчермәсен күрсәтеп, хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлекне гамәлгә ашырганда юридик затлар, шәхси эшкуарлар һәм гражданнар тарафыннан кулланыла торган территорияләргә, биналарга, урыннарга, корылмаларга, шул исәптән чистарту корылмаларына үтеп керергә һәм аларны тикшерергә, зарарсызландыра торган башка җайланмаларны, тикшереп тору чараларын, техник һәм транспорт чараларын, җайланмаларны һәм материалларны тикшерергә, шулай ук күзәтчелек буенча кирәкле тикшеренүләрне, сынауларны, үлчәм алу, эзләтү эшләрен, экспертизалар уздырырга;

3) 294-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә прокуратура органнары белән тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза җибәрергә;

4) юридик затларга, шәхси эшкуарларга һәм гражданнарга ачыкланган мәҗбүри таләпләрне бозуларны бетерү турында күрсәтмәләр бирергә, үсемлекләргә, хайваннарга, әйләнә-тирә мохиткә, дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләт яисә муниципаль милеккә зыян китерүне тәэмин итү, табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне булдырмау буенча чаралар үткәрү турында күрсәтмә бирергә;

5) зарури таләпләрне бозуга бәйле административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзергә, күрсәтелгән административ хокук бозулар турында эшләрне карарга һәм мондый бозуларны бетерү буенча чаралар күрергә;

6) җинаять билгеләре буенча җинаять эшләре кузгату турында мәсьәләләрне хәл итү өчен, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге законнар бозылуга бәйле материалларны вәкаләтле органнарга җибәрергә;

7) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә әйләнә-тирә мохиткә һәм аның компонентларына зарури таләпләр бозылу аркасында китерелгән зыянны каплау турында дәгъвалар белдерергә.

8) калдыклар белән эш итү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле гражданнарны, юридик һәм вазыйфаи затларны административ җаваплылыкка тартырга;

9) дәүләт инспекторлары тарафыннан законлы эшчәнлекне гамәлгә ашыруга комачаулаучы гамәлләрне булдырмауда яисә туктатуда, шулай ук калдыклар белән эш итү өлкәсендә Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле затларны билгеләүдә ярдәм сорап Эчке эшләр органнарына мөрәҗәгать итәргә.

1.5.2. ТР ЭТРМның табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары булып торган вазыйфаи затлары тикшерү үткәргәндә түбәндәгеләрне бурычлы:

1) зарури таләпләр бозылуны кисәтү, ачыклау һәм чикләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә тапшырылган вәкаләтләрне үз вакытында һәм тулы дәрәҗәдә башкарырга;

2) Россия Федерациясе законнарын, үзләренә карата тикшерү уздырыла торган юридик затның, шәхси эшкуарның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен сакларга;

4) тикшерүне бары тик хезмәт вазыйфаларын үтәү вакытында гына, күчмә тикшерүне бары тик хезмәт таныкларын, министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) күчермәсен һәм, 294-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 5 өлешендә каралган очракта, тикшерү уздыруның килештерелгән булуы турында документ күчермәсен күрсәткәндә генә үткәрергә;

5) юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерүне үткәргәндә катнашуына һәм тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләрдә аңлатмалар бирүенә каршы килмәскә;

6) тикшерүне үткәргәндә катнашучы юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә тикшерү предметына кагыла торган мәгълүматларны һәм документларны бирергә;

7) юридик зат җитәкчесен, башка вазыйфаи затын яисә вәкаләтле вәкилен, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен тикшерү нәтиҗәләре белән таныштырырга;

8) ачыкланган бозулар буенча күрелә торган чараларны билгеләгәндә әлеге чараларның бозуларның катлаулылыгына, аларның кешеләрнең гомере, сәламәтлеге, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре), дәүләт иминлеге өчен потенциаль куркыныч булуын , табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүе өчен булуына туры килүен исәпкә алырга, шулай ук гражданнарның, шул исәптән шәхси эшкуарларның, юридик затларның хокуклары һәм законлы мәнфәгатьләре нигезсез рәвештә чикләнүенә юл куймаска;

9) юридик затлар, шәхси эшкуалар тарафыннан шикаять белдерелгәндә үз гамәлләренең нигезле булуын Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә дәлилләргә;

10) 294-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тикшерүне үткәрү срокларын үтәргә;

11) юридик заттан, шәхси эшкуардан Россия Федерациясе законнарында тапшырылуы каралмаган документларны һәм башка белешмәләрне таләп итмәскә;

12) күчмә тикшерү уздыра башлар алдыннан юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиленең гозере буенча аларны тикшерү уздыруга нигез булган әлеге Регламент кушымталары белән таныштырырга;

13) уздырылган тикшерү турында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентының 8 нче кушымтасында китерелгән үрнәк буенча (булган очракта) тикшерүләрне исәпкә алу журналында язу теркәргә;

1.5.3. ТР ЭТРМ табигатьне саклау буенча Татарстан Республикасы дәүләт инспекторлары булып торган вазыйфаи затлары хокуклы түгел:

1) әгәр бу таләпләр ТР ЭТРМ вәкаләтләренә карамаса, аның исеменнән гамәл кылучы вазыйфаи затлар буларак, зарури таләпләр үтәлешен тикшерергә;

2) кешеләрнең гомере, сәламәтлеге, хайваннар, үсемлекләр, әйләнә-тирә мохит, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре), дәүләт иминлеге өчен зыян салыну, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү нигезендә уздырылган тикшерү очрагыннан тыш, тикшерү уздырганда юридик зат җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очакта, планлы яки планнан тыш күчмә тикшерүне гамәлгә ашырырга;

3) әгәр алар тикшерү объектлары булып тормаса яисә тикшерү предметына карамаса, документлар, мәгълүматлар, продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын тапшыруны таләп итәргә, шулай ук мондый документларның нөсхәләрен алырга;

4) продукция үрнәкләрен, әйләнә-тирә мохит объектларын һәм җитештерү тирәлеге объектларын тикшерү пробаларын аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу өчен әлеге үрнәкләрне, пробаларны алу турында беркетмәләрне билгеләнгән рәвешендә рәсмиләштермичә һәм илкүләм стандартларда, үрнәкләрне, пробаларны алу кагыйдәләрендә һәм аларга тикшеренүләр, сынаулар уздыру, үлчәмнәр алу методларында, техник регламентларда яисә алар үз көченә кергән көнгә кадәр гамәлдә булган башка норматив техник документларда һәм тикшеренүләр, сынаулар, үлчәмнәр алу кагыйдәләрендә һәм методларында билгеләнгән нормалардан артып китүче санда алырга;

5) тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә алынган һәм дәүләт, коммерция, хезмәт серен, закон белән саклана торган башка төрле серне тәшкил итүче мәгълүматларны таратырга, Россия Федерациясе законнарында каралган очраклардан тыш;

6) тикшерү үткәрүнең билгеләнгән вакытларын арттырырга;

7) юридик затларга, шәхси эшкуарларга алар хисабына контрольлек чараларын үткәрү турында күрсәтмәләр яки тәкъдимнамәләр бирергә;

8) СССР һәм РСФСР башкарма хакимияте органнарының норматив хокукый актларында билгеләнгән һәм Россия Федерациясе законнарына туры килми торган таләпләрнең үтәлешен тикшерергә;

9) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарылмаган зарури таләпләрнең һәм муниципаль хокукый актларда билгеләнгән таләпләрнең үтәлешен тикшерергә.

1.6. Дәүләт күзәтчелеге буенча чаралар гамәлгә ашырыла торган затларның хокуклары һәм бурычлары.

1.6.1. Тикшерү уздырылганда юридик зат җитәкчесенең, башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең хокуклары:

1) тикшерүне үткәргәндә турыдан-туры катнашырга, тикшерү предметына кагыла торган мәсьәләләр буенча аңлатмалар бирергә;

2) ТР ЭТРМ, андагы вазыйфаи затлардан тикшерү предметына кагыла торган һәм бирелеше 294-ФЗ номерлы федераль законда каралган мәгълүматларны алырга;

3) тикшерү нәтиҗәләре белән танышырга һәм тикшерү актында тикшерү нәтиҗәләре белән үзенең танышуы, алар белән, шулай ук ТР ЭТРМ вазыйфаи затларының аерым гамәлләре белән ризалашуы яки ризалашмавы турында күрсәтергә. Тикшерү актында бәян ителгән фактлар, нәтиҗәләр, тәкъдимнәр белән яисә ачыкланган бозуларны бетерү турында бирелгән күрсәтмә белән риза булмаган очракта, тикшерү актын алган датадан соң унбиш көн эчендә ТР ЭТРМ тикшерү актына һәм (яисә) бирелгән ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмәгә карата тулаем яисә аның аерым нигезләмәләренә карата язмача рәвештә ризасызлыклар тапшырырга хокуклы. Шул ук вакытта юридик зат, шәхси эшкуар мондый ризасызлыкларга шушы ризасызлыкларның нигезле булуын раслый торган документларны яисә аларның таныкланган күчермәләрен теркәргә яисә аларны килешенгән вакытта дәүләт контроле (күзәтчелеге) органына, муниципаль контроль органына тапшырырга хокуклы. Әлеге документлар тикшерелә торган затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ (электрон документлар пакеты) рәвешендә дә җибәрелергә мөмкин;

4) тикшерү уздырганда ТР ЭТРМ вазыйфаи затларының юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китереп чыгарган гамәлләренә (гамәл кылмауларына) Россия Федерациясе законнары нигезендә административ һәм (яки) суд тәртибендә шикаять белдерергә;

5) Россия Федерациясе Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне яисә Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Шәхси эшкуарларның хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилне тикшерүдә катнашуга җәлеп итәргә.

1.6.2. Юридик зат җитәкчесенең, аның башка вазыйфаи затының яки вәкаләтле вәкиленең, шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең тикшерү уздырганда бурычлары:

1) тикшерү уздыруга вәкаләтле вазыйфаи затлар тарафыннан сорала торган документларны һәм материалларны тапшыру, шулай ук тикшерү предметына кагылышлы мәсьәләләрдә телдән һәм язмача аңлатмалар бирү;

2) күчмә тикшерүне уздыра торган вазыйфаи затлар һәм күчмә тикшерүдә катнаша торган экспертлар, экспертлар вәкилләре өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан эшчәнлекне гамәлгә ашырганда кулланыла торган территориягә, бинага, корылмага, төзелмәгә, бүлмәгә, юридик зат, шәхси эшкуар куллана торган җайланмага, шуңа охшаш объектларга, транспорт чараларына һәм алар ярдәмендә ташыла торган йөкләргә үтеп керүне тәэмин итәргә;

3) катнашырга яисә зарури таләпләрне үтәү буенча чараларны оештыру һәм үткәрү өчен җаваплы булган вәкаләтле вәкилләрнең катнашуын тәэмин итәргә.

1.7. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләрен тасвирлау.

Планлы, планнан тыш тикшерү нәтиҗәләре буенча ТР ЭТРМның тикшерү үткәрүче вазыйфаи затлары тарафыннан түбәндәге документлар төзелә:

юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан калдыклар белән эш итү өлкәсендәге законнарның, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен билгеләнгән түләү срокларының үтәлешен тикшерү турында Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентының 1 нче кушымтасында китерелгән билгеләнгән форма буенча ике нөсхәдә акт;

Административ хокук бозулар турында РФ кодексында каралган хокукны бозу турында әлеге Регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән форма буенча ТР ЭТРМ компетенциясе чикләрендә (хокук бозу факты ачыкланган очракта) административ хокук бозу турында беркетмә;

әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән форма буенча калдыклар белән эш итү өлкәсендәге законнарны, җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен билгеләнгән түләү срокларын бозу очракларын бетерү (бозу факты ачыкланган очракта) турында күрсәтмә.

ТР ЭТРМ вазыйфаи затлары тарафыннан тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) күчмә тикшерү турында язу теркәлә.

Әгәр дәүләт функциясен үтәү өчен ТР ЭТРМ гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан (алга таба – мөрәҗәгать итүче) килгән мәгълүматлар нигез булып хезмәт итсә, дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәләре буенча мөрәҗәгать итүчегә 59-ФЗ номерлы федераль законда билгеләнгән тәртиптә җавап җибәрелә.

Тикшерү уздырганда зарури таләпләр бозылу очраклары ачыкланган очракта ТР ЭТРМ вазыйфаи затлары, Россия Федерациясе законнарында каралган вәкаләтләреннән чыкмыйча, ачыкланган бозуларны бетерү, аларны кисәтү, гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салыну ихтималын чикләү, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүне кисәтү буенча контрольлек чараларын; шулай ук ачыкланган бозуларга юл куйган затларны җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә.

Күзәтчелек чаралары нәтиҗәсендә, затның гамәлләрендә (гамәл кылмавында) административ хокук бозу составына караучы билгеләр булганда, гаепле затка карата Административ хокук бозулар турында РФ кодексында билгеләнгән тәртиптә административ эш кузгатыла.

Әгәр тикшерү уздырганда тикшерелә торган затның эшчәнлеге турыдан-туры гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салу, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү куркынычын тудыруы ачыкланса яисә мондый зыян салынган булса, ТР ЭТРМ кичекмәстән зыян салынга юл куймау яки, Административ хокук бозулар турында РФ кодексында

билгеләнгән тәртиптә затның эшчәнлеген вакытлыча тыю, гражданнарның гомере, сәламәтлеге өчен һәм әйләнә-тирә мохит өчен куркыныч тудыра торган продукцияне әйләнештән алу һәм гражданнарга, шулай ук башка юридик затларга, шәхси эшкуарларга мөмкин булган теләсә нинди ысул белән зыян салыну куркынычы барлыгы һәм аны туктату ысуллары турында мәгълүмат җиткерү өлешенә кадәр, зыян салынуны туктату буенча чаралар күрә.

Күзәтчелек чараларын уздыру барышында җинаять билгеләре ачыкланган очракта, калдыклар белән эш итү өлкәсендә законнар бозылуга бәйле материалларны җинаять эшләрен кузгату турында мәсьәләне хәл итү өчен вәкаләтле органнарга җибәрү турында мәсьәлә хәл ителә.

## 2. Дәүләт функцияләрен үтәү тәртибенә карата таләпләр

### 2.1. Дәүләт функциясенең үтәлеше турында мәгълүмат бирү тәртибе

2.1.1. Әлеге Регламент «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә (алга таба – «Интернет» челтәре) www.eco.tatar.ru – ТР ЭТРМ рәсми сайтында урнаштырыла.

2.1.2. ТР ЭТРМ урнашу урыны: Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75.

Белешмәләр өчен ТР ЭТРМ телефоннары: Тел. 267-68-01, 267-68-70

Мөрәҗәгатьләрне юллау өчен электрон адрес: http://eco.tatar.ru/.

ТР ЭТРМ дәүләт функциясен гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләренең урнашу урыннары турындагы мәгълүмат 2.1 нче таблицада китерелә.

2.1 нче таблица. Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының дәүләт функциясен гамәлгә ашыручы структур бүлекчәләре турында белешмәләр

| Территориаль орган | Адрес | Хезмәт күрсәтә торган территорияләре | Телефон |
|---|---|---|---|
| Дәүләт экологик күзәтчелек инспекциясе | 420049, Казан шәһәре, Павлюхин ур., 75 | Татарстан Республикасы | 267-68-67<br>264-34-89 |
| Үзәк территориаль идарә (алга таба – Үзәк территориаль идарә) | 420049, Казан шәһәре, Павлюхин ур., 75 | Казан ш., Биектау муниципаль районы (алга таба – МР),<br>Лаеш МР<br>Питрәч МР<br>Югары Ослан МР<br>Балык Бистәсе МР<br>Саба МР<br>Теләче МР,<br>Зеленодольск МР | 267-68-33 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Төньяк территориаль идарәсе | 422000, Арча шәһәре, Интернациональная урамы, 41, | Арча шәһәре,<br>Әтнә МР<br>Арча МР<br>Балтач МР<br>Кукмара МР | (84 366)<br>3-21-61 |
| Идел аръягы территориаль идарәсе | 422430, Буа шәһәре, Р. Люксембург ур., 159/1 | Буа шәһәре,<br>Буа МР<br>Чүпрәле МР<br>Апас МР<br>Кайбыч МР<br>Кама Тамагы МР<br>Тәтеш МР, | (84 374)<br>3-11-02<br>3-34-46 |
| Идел-Кама территориаль идарәсе | 422980, Чистай шәһәре, Фрунзе ур., 97а | Чистай шәһәре,<br>Аксубай МР<br>Алексеевск МР<br>Әлки МР<br>Спас МР<br>Чистай МР<br>Яңа Чишмә МР | (84 342)<br>5-35-19<br>5-03-68 |
| Кама аръягы территориаль идарәсе | 423552, Түбән Кама районы, Красный Ключ пос., Набережная ур., 7 | Түбән Кама шәһәре,<br>Түбән Кама МР<br>Зәй МР<br>Сарман МР, | (88 555)<br>45-66-56<br>43-90-70 |
| Кама буе территориаль идарәсе | 423838, Чаллы шәһәре, Җиңүнең 40 еллыгы ур., 64 | Чаллы шәһәре,<br>Әгерҗе МР<br>Менделеевск МР<br>Минзәлә МР,<br>Тукай МР<br>Мамадыш МР<br>Алабуга МР<br>Актаныш МР, | (8-8552)<br>59-36-39<br>59-50-46 |
| Ык буе территориаль идарәсе | 423330, Азнакай шәһәре, Шоссейная ур., 6 | Азнакай МР,<br>Актүбә штп<br>Азнакай МР<br>Баулы МР<br>Мөслим МР<br>Ютазы МР | (8-85572)<br>2-39-86<br>(8-85592)<br>51-5-38 |
| Көньяк- | 423450, Әлмәт | Әлмәт шәһәре, | (8- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| Көнчыгыш территориаль идарәсе | шәһәре, Әминов ур., 9а | Бөгелмә МР<br>Лениногорск МР<br>Нурлат МР<br>Чирмешән МР | 8553)<br>33-03-25<br>33-03-27 |

2.1.3. ТР ЭТРМ дәүләт функцияләрен үтәү мәсьәләләре буенча документлар һәм мөрәҗәгатьләр җибәрү өчен почта адресы: 420049, Казан шәһәре, Павлюхин урамы, 75

2.1.4. ТР ЭТРМ (ТР ЭТРМ ҮТИ кертеп) эш графигы:

Дүшәмбе-пәнҗешәмбе: 9.00 сәгатьтән 18.00 сәгатькә кадәр,

Җомга 9.00 сәгатьтән 16.45 сәгатькә кадәр.

Төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

ТР ЭТРМ территориаль идарәләренең эш графигы:

Дүшәмбе-пәнҗешәмбе 8.00 сәгатьтән 17.00 сәгатькә кадәр;

Җомга: 8.00 башлап 15.45 кадәр.

Төшке аш: 12.00 сәгатьтән 12.45 сәгатькә кадәр.

Ял көннәре: шимбә, якшәмбе.

2.1.5. ТР ЭТРМ, ТР ЭТРМ Дәүләт экологик күзәтчелек инспекциясе һәм ТР ЭТРМ территориаль органнары урнашкан урын, аларның телефоннары һәм эш графигы турында мәгълүмат «Интернет» челтәрендәге http://eco.tatar.ru/ сайтында һәм ТР ЭТРМ фойесында, шулай ук дәүләт функциясен башкара торган ТР ЭТРМ территориаль идарәләре коридорларында, холларында, фойесында урнаштырылган мәгълүмат стендларында урын алган. Әлеге мәгълүмат шулай ук түбәндәгечә дә бирелә:

әлеге телефоннар буенча: министрның кабул итү бүлмәсе - 267-68-01;

Дәүләт экологик күзәтчелек инспекциясе – 267-68-67.

Әлеге Регламент турында белешмәләр Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының рәсми сайтында урнаштырылган Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары тарафыннан дәүләт функцияләрен үтәүнең административ регламентларының бердәм реестрына кертелә http://mert.tatarstan.ru.

Дәүләт функциясен үтәү турында мәгълүмат дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар тарафыннан бирелә:

- шәхси кабул итү кысаларында турыдан-туры;

- язмача рәвештә (шушы Регламентның 2.1.3 пунктында күрсәтелгән реквизитлар буенча почта аша мөрәҗәгать иткәндә);

- электрон почта аша eco@tatar.ru;

- «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы» дәүләт мәгълүмат системасында (http://uslugi.tatarstan.ru/) (алга таба – Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталы);

Дәүләт функциясен үтәү тәртибе турында мәгълүмат ТР ЭТРМ рәсми сайтында, ТР ЭТРМ һәм аның дәүләт функциясен башкара торган территориаль

органнарының гражданнарны кабул итү гамәлгә ашырыла торган бүлмәләрендәге стендларда урнаштырыла һәм (әлеге Регламентка үзгәрешләр кертү дәрәҗәсенә карап) яңартыла.

2.1.6. Гавами рәвештә телдән мәгълүмат җиткерү массакүләм мәгълүмат чаралары – радионы, телевидениене җәлеп итеп гамәлгә ашырыла. Радио һәм телевидение буенча мәгълүмат бирү өчен җаваплы белгечләрнең чыгышлары министр белән килештерелә.

2.2. Юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан дәүләт контроле (күзәтчелеге) чараларын үткәргән өчен түләү алуның ярамаганлыгы хакында

Дәүләт күзәтчелеге буенча чаралар үткәргән өчен юридик затлардан, шәхси эшкуарлардан түләү алынмый, шул исәптән тикшерүләрне үткәрү өчен җәлеп ителгән очракта, экспертларның һәм эксперт оешмаларының хезмәтләре өчен дә.

2.3. Дәүләт функциясен үтәү вакыты

2.3.1. Тикшерүне (документар (планлы яки планнан тыш), шулай ук күчмә (планлы яки планнан тыш) үткәрү вакыты 20 эш көненнән артмаска тиеш.

Кече эшкуарлыкның бер субъектына карата планлы күчмә тикшерүләр үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен илле сәгатьтән һәм микропредприятие өчен унбиш сәгатьтән артык була алмый.

Искәрмәле, катлаулы һәм (яисә) озак вакытлы тикшеренүләрне, махсус экспертизаларны һәм тикшерүләрне үткәрү зарурлыгына бәйле булган очракларда, ТР ЭТРМ күчмә планлы тикшерүне үткәрүче вазыйфаи затларының нигезләнгән тәкъдимнәре нигезендә, планлы күчмә тикшерүне үткәрү вакыты министр тарафыннан озынайтылырга мөмкин, ләкин егерме эш көненнән дә артыграк булган чорга түгел, кече предприятиеләр өчен иң күбе – илле сәгатькә, микропредприятиеләр өчен иң күбе – унбиш сәгатькә.

Россия Федерациясенең берничә субъекты территориясендә үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затка карата тикшерү (документар, күчмә) уздыру вакыты юридик затның һәр филиалы, вәкиллеге, аерымланган структур бүлекчәсе өчен аерым билгеләнә, бу вакытта тикшерү уздыруның гомуми вакыты алтмыш эш көненнән артык була алмый.

2.3.2. Планлы тикшерүләр өч елга бер тапкырдан да ешрак үткәрелми.

2.4. Тикшерүләр үткәрү өчен нигезләр

2.4.1. Планлы тикшерүләр ТР ЭТРМ тарафыннан эшләнелә торган тикшерүләр планы нигезендә үткәрелә.

ТР ЭТРМ планлы тикшерүләр үткәрү елыннан алдагы елның 1 сентябренә кадәр ел саен планлы тикшерүләр үткәрү планнарының (алга таба — планнар) проектларын прокуратура органнарына җибәрә.

Планлы тикшерүне Планга кертү нигезе булып түбәндәге көннән башлап өч елның узып китүе тора:

1) юридик затны, шәхси эшкуарны дәүләт теркәвенә алган көннән башлап;

2) юридик затка, шәхси эшкуарга карата үткәрелгән соңгы планлы тикшерүне уздыру тәмамлангач;

3) юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тиешле өлкәдә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органына эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында тапшырылган белдерүнамәгә ярашлы рәвештә, күрсәтелгән белдерүнамәне тапшыруны таләп итә торган эшләр башкарылган яисә хезмәтләр күрсәтелгән очракта, эшкуарлык эшчәнлеге гамәлгә ашырыла башлагач.

Юридик затка, шәхси эшкуарга карата тикшерү уздыру турында министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентының 4 нче кушымтасында китерелгән бер төр форма буенча рәсмиләштерелә.

2.4.2. Планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып тора:

1) зарури таләпләр бозылуның ачыкланган очрагын юкка чыгару турында элегрәк бирелгән күрсәтмәнең юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан үтәү вакытының узып китүе;

2) ТР ЭТРМ гражданнардан, шул исәптән шәхси эшкуарлардан, юридик затлардан, дәүләт хакимияте органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан, массакүләм мәгълүмат чараларыннан лицензиатның лицензия таләпләрен тупас бозу фактлары турында мәгълүмат алынуы;

а) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салыну куркынычы, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр куркынычы барлыкка килүе;

б) гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян салынуы, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирәлеккә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян салынуы, шулай ук табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүе;

в) кулланучылар хокукларын бозу (хокуклары бозылган гражданнар мөрәҗәгать иткән очракта);

ое) Россия Федерациясе Президенты, Россия Федерациясе Хөкүмәте йөкләмәләренә туры китереп һәм прокурорның прокуратура органнарына килгән материаллар һәм мөрәҗәгатьләр буенча законнарның үтәлешенә күзәтчелек итү кысаларында планнан тыш тикшерү үткәрү турындагы таләбе нигезендә чыгарылган боерык.

ТР ЭТРМ мөрәҗәгать итүченең затын билгеләргә мөмкинлек бирми торган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар, шулай ук әлеге югарыда күрсәтелгән фактлар турында белешмәләре булмаган мөрәҗәгатьләр һәм гаризалар планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигез булып хезмәт итә алмый.

Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планнан тыш күчмә тикшерү ТР ЭТРМ тарафыннан әлеге пунктның «а» һәм «б» пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр буенча, мондый юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлекләре гамәлгә

ашырылу урыны буенча, прокуратура органы белән килештергәннән соң үткәрелергә мөмкин.

ТР ЭТРМ юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны прокуратура органы белән килештерүе турында гариза бер төр формада рәсмиләштерелә.

2.5. Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар

Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлеге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының һәм Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлары исемлекләрен раслау турында» 2011 елның 21 сентябрендәге 784 номерлы карары белән расланган.

**2.2 нче таблица**

2.6. 294-ФЗ номерлы федераль законны бозган өчен юридик затларның, шәхси эшкуарларның җаваплы булуы

294-ФЗ номерлы федераль закон бозылуга юл куйган, тикшерүләрне үткәрүгә нигезсез рәвештә каршы төшүче, тикшерүләрне үткәрүдән качып йөрүче һәм (яки) билгеләнгән чорларда ТР ЭТРМ зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәсен үтәмәүче юридик затлар, аларның җитәкчеләре, бүтән вазыйфаи затлары яки вәкаләтле вәкилләре, шәхси эшкуарлар, аларның вәкаләтле вәкилләре Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы була.

2.7. Тикшерү барышында ТР ЭТРМ, аның вазыйфаи затларының җаваплылыгы

ТР ЭТРМ, андагы вазыйфаи затлар тикшерү үткәргәндә, тиешенчә, функцияләрне, хезмәт вазыйфаларын тиешле дәрәҗәдә үтәмәгән очракта, хокукка каршы килә торган гамәлләрне кылганда (гамәл кылмаганда), Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплы булалар.

Россия Федерациясе законнарын бозуда гаепле вазыйфаи затларга карата күрелгән чаралар турында мондый чаралар күрелгән көннән соң ун көн эчендә ТР ЭТРМ язмача рәвештә хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итәргә бурычлы.

3. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата куелган зарури таләпләр

Дәүләт күзәтчелеген уздырганда юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата белдерелә торган, үтәлеше тикшерүдә тотылган зарури таләпләрнең, аларны билгели торган норматив хокукый актларның, тикшерү барышында юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан күрсәтелә торган документларның исемлеге 3 нче таблицада китерелгән.

3 нче таблица. Юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге

| Таләпләр төре | Зарури таләпнең тәгъбирләнеше | Зарури таләпне билгели торган норматив хокукый акт | Тикшерү вакытында юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге |
|---|---|---|---|
| 1. Җитештерү һәм куллану калдыклары (алга таба – ҖКК) белән эш итү өлкәсендә экология таләпләрен үтәү | 1.1. ҖКК барлыкка килүне регламентлаучы документлар, төп һәм ярдәмче, хезмәт күрсәтү процесслары һәм операцияләре өчен стандартлар, техник шартлар, технологик регламентлар булу (җитештерү балансы, планы, (экологик үсеш), җитештерү структурасы буенча тикшерелә) | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 1 ст. | җитештерү структурасы;<br>технологик регламентларда (технологик карталарда) аерым технологик процесслар буенча барлыкка килә торган калдыклар номенклатурасы һәм күләме;<br>предприятие буенча тулаем алганда калдыклар барлыкка килүен чагылдыра торган баланс схемалары яисә матди агым схемалары булу;<br>җитештерү (экологик үсеш) планы;<br>калдыкларны инвентаризацияләү нәтиҗәләре;<br>продукция җитештерүгә технологик регламентлар;<br>стандартлар, продукциягә техник шартлар |
| | 1.2. Хокук билгели торган, лицензия документлары (I-IV класслы куркыныч калдыкларын җыю, транспортлау, эшкәртү, | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 4.1 ст., 9 ст.; | җир кишәрлегенә ия булу яки аннан файдалану хокукы өчен документлар;<br>куркыныч калдыкларны җыю, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру буенча эшчәнлекне тормышка ашыруга лицензия |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру буенча лицензияләр булуы тикшерелә) | «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль законның 12 ст.;<br>Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 3 октябрендәге 1062 номерлы карары белән расланган I-IV класслы куркынычлык калдыкларын җыю, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә;<br>РФ Хөкүмәтенең «Лицензиянең бер төр рәвешен раслау турында» 2011 елның 6 октябрендәге 826 номерлы карары | (шул исәптән куркыныч калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру һәм урнаштыру эшчәнлеге составында куркыныч калдыклар исемлеге һәм эш төрләре);<br>куркыныч калдыкларны җыю, ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлегенә бирелгән лицензияләр реестрыннан өземтә |
| | 1.3. Лицензияләүче | «Эшчәнлекнең | лицензиат тарафыннан куркыныч |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | органны тикшерү нәтиҗәләре буенча лицензия таләпләрен үтәү | аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы федераль закон<br>2007 елның 10 декабрендәге 848 номерлы Ростехнадзор боерыгы белән расланган Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең куркыныч калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, ташу, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты | калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, ташу, урнаштыру эшчәнлеген гамәлгә ашырганда таләпләрне һәм шартларны үтәүгә карата тикшерү уздыру актлары (теркәлә торган документлар белән: продукция үрнәкләрен (пробалар) алу, әйләнә тирә мохит объектларын тикшерү турында актлар, уздырылган тикшеренүләр (сынаулар) һәм экспертизалар беркетмәләре (бәяләмәләре), зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы вазыйфаи затларының аңлатмалары һәм контрольлек чарасы нәтиҗәләре белән бәйле башка документлар яки аларның күчермәләре);<br>контрольлек чараларын исәпкә алу журналы |
| | шул исәптән лицензия таләпләрен һәм шартларын тикшерү | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 3 октябрендәге 1062 номерлы карары белән расланган I-IV класслы куркынычлык | лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле техник нормаларга һәм таләпләргә туры килә торган җитештерү бүлмәләренең, калдыкларны урнаштыру объектларының, җиһазларның, транспорт чараларының булуын раслаучы документлар; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | калдыкларын җыю, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә | куркыныч калдыклар белән эш итү эшчәнлегенә кертелгән затлар өчен куркыныч калдыклар белән эшләү хокукына таныклыклар (сертификатлар): калдыклар урнаштыру һәм зарарсызландыру белән бәйле объектларның проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе (2008 елның 30 декабрендәге 309-ФЗ номерлы федераль закон үз көченә кергәнче файдалануга тапшырылган яки төзелешенә рөхсәт бирелгән объектлардан тыш) |
| | 1.4. Чыгарыла торган продукциянең билгеле бер төренә технологик регламентка салынган калдыкларның төр составы һәм күләменең туры килүе, шул исәптән калдыклар барлыкка килү нормативлары проекты һәм аларны урнаштыру лимитлары булуы | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 18 ст.; Россия Табигать министрлыгының 349 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү | федераль классификация каталогы нигезендә предприятиедә барлыкка килә торган калдыклар исемлеге; җитештерелә торган продукциянең билгеле бер төренә технологик регламент; җитештерү контроле нәтиҗәләре; калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проекты (калдыклар урнаштыруга рөхсәт ителгән калдыкларның исемлеге һәм саны турында белешмәләр); Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектын карау нәтиҗәләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | буенча методик күрсәтмәләр;<br>РФ Табигать министрлыгының 2011 елның 1 сентябрендәге 721 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар белән эш итү өлкәсендә исәпкә алу тәртибе | буенча бәяләмә;<br>җитештерү процессының, кулланыла торган чималның һәм барлыкка килә торган калдыклар турында үзгәрешсезлеге турында техник хисап (калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проекты белешмәләрен раслау);<br>җитештерү процессының, кулланыла торган чимал һәм барлыкка килә торган калдыклар турында техник хисапны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә;<br>Калдыкларны урнаштыру, шул исәптән калдыкларны урнаштыру объектларында урнаштыру лимитлары;<br>калдыклар урнаштыру объектларында урнашкан калдыклар исемлеге һәм саны;<br>калдыкларны урнаштыру объектларында урнаштыру лимиты);<br>предприятие территориясендә вакытлыча туплана торган калдыкларның исемлеге һәм саны;<br>калдыкларны исәпкә алу мәгълүматлары |
| | 1.5. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү контролен | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 | Җитештерү контролен махсус төзелгән хезмәткә яисә билгеләнгән җаваплы затка йөкләү турында юридик зат |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | гамәлгә ашыру буенча эшне оештыру | июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 26 ст. | боерыгы (күрсәтмәсе);<br>махсус төзелгән (экологик) хезмәт турында нигезләмә;<br>экология хезмәте хезмәткәрләренең (экологның) вазыйфаи күрсәтмәләре;<br>экология хезмәте хезмәткәрләренең (экологның) зарури һөнәри әзерлеген яисә яңадан әзерләнүен раслаучы документлар;<br>калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү контролен оештыру һәм уздыру тәртибе (предприятиенең (оешманың) экологик контроле турында юридик зат тарафыннан расланган нигезләмә составында);<br>предприятиедә җитештерү контроленең план-графигы;<br>җитештерү контроле нәтиҗәләре;<br>предприятие лабораториясен аккредитацияләү турында аттестат күчермәсе (лаборатория булган очракта) |
| | 1.6. ҖКК белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыручы дәүләт инспекторларының ҖКК белән эш итү өлкәсендә Россия Федерациясе | 294-ФЗ номерлы федераль законның 25 ст. 2 өлеше | ҖКК белән эш итү өлкәсендә дәүләт контролен гамәлгә ашырганда предприятиегә уздырылган алдагы тикшерүләр нәтиҗәләре буенча документлар;<br>алдагы тикшерүләр нәтиҗәсендәге актлар һәм күрсәтмәләр; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | законнары таләпләре бозылуны бетерү турында күрсәтмәләрен үтәү | | административ хокук бозулар турында беркетмәләр (карарлар);<br>табигать саклау законнары бозылуны бетерү буенча предприятие буенча боерыклар һәм чаралар планнары;<br>табигать саклау законнары бозылуны бетерү буенча чаралар үтәлеше турында хисаплар |
| | 1.7. ҖКК барлыкка килүен исәпкә алуны һәм алар белән эш итүне алып бару һәм анық билгеләнгән таләпләргә туры килү-килмәве | РФ Табигать министрлыгының 2011 елның 1 сентябрендәге 721 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар белән эш итү өлкәсендә исәпкә алу тәртибе | калдыкларны исәпкә алу мәгълүматлары |
| | 1.8. ҖКК барлыкка килү һәм анық белән эш итүне беренчел исәпкә алуны алып бару | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 19 ст. | технологик регламентларда (технологик карталарда) аерым технологик процесслар буенча барлыкка килә торган калдыклар номенклатурасы һәм күләме;<br>предприятие буенча тулаем алганда калдыклар барлыкка килүен чагылдыра торган баланс схемалары яисә матди агым схемалары булу;<br>продукция берәмлегенә калдыклар барлыкка килүнең тармак нормативлары булу; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | РФ Табигать министрлыгының 2011 елның 1 сентябрендәге 721 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар белән эш итү өлкәсендә исәпкә алу тәртибе | технологик җиһазларның факттагы эш вакытын исәпкә алу;<br>җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килүне, аларны җыюны, туплауны, файдалануны, зарарсызландыруны (юкка чыгаруны), тапшыруны (сатуны), урнаштыруны (күмүне) исәпкә алу белешмәләре;<br>технологик процесс регламенты (өзлексез техник процесс өчен) (исәпкә алу срокларын тикшерү өчен) |
| | 1.9. Агулы җитештерү һәм куллану калдыкларының куркынычлылык классы билгеләнгән таләпләргә туры килүен раслаучы документлар булу | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 14 ст.;<br>Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең 2006 елның 8 апрелендәге аңлатмасы | калдыкның әйләнә-тирә мохит өчен куркынычлылык классы турында таныклыклар, яисә куркыныч калдыкларның паспортлары, яисә калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары |
| | 1.10. Куркыныч калдыкларның паспорты | «Җитештерү һәм куллану калдыклары | куркыныч калдыкларның паспортлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | булу (паспорт кем тарафыннан эшләнгән, кайчан килештерелгән, кайсы чорга) | турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 1 ст., 14 ст.; ГОСТ Р 53691-2009 РФ Илкүләм стандарты, 1091-ст номерлы боерык белән расланган; РФ Хөкүмәтенең 712 номерлы карары; Росприроднадзорның 445 номерлы карары белән расланган Федераль классификацион каталог | |
| | 1.11. Агулы калдыкларның куркыныч классының билгеләнгән таләпләргә туры килүе | РФ Хөкүмәтенең 712 номерлы карары; Россия Табигать министрлыгының 511 номерлы боерыгы белән расланган Куркыныч калдыкларны әйләнә-тирә табигый мохит өчен куркынычлылык классына кертү критерийлары; Табигатьтән файдалану өлкәсендә | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең 441 номерлы боерыгы | |
| | 1.12. Инвентаризация үткәрү (кайчан үткәрелгән, башкаручы, ышанычнамә) | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 11 ст. | инвентарьлаштыру буенча хисап |
| | 1.13. Предприятие (оешма) территориясендә агулы сәнәгать калдыклары җыелуның ҖКК барлыкка килүнең иң чик нормаларына туры килүе, предприятиедә (оешмада) ҖКК җыю объектларын урнаштыру, кору һәм карап тотуга карата билгеләнгән таләпләрне үтәү | СанПиН 2.1.7.1322-03 «Җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштыруга һәм зарарсызландыруга карата гигиена таләпләре» | җитештерү территориясендә сәнәгый калдыкларны җыю һәм туплау шартларын үз эченә алган техник регламент (проект, предприятие паспорты, ТУ, күрсәтмәләр) |
| | 1.14. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә бирелә торган мәгълүматның дөреслеге һәм калдыклар турында хисап тоту | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 1.15. Билгеләнгән тәртиптә һәм билгеләнгән срокта статистик хисаплылык тапшыру | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 19 ст. | |
| | 1.16. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә бирелә торган мәгълүматның дөреслеге һәм статистик хисаплылык формаларын тутыруның дөреслеге | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 25 ст.;<br>«Җитештерү һәм куллану калдыкларына федераль статистика күзәтчелеген оештыру өчен статистик инструментарийны раслау турында» 2011 елның 28 гыйнварындагы 17 номерлы Росстат боерыгы | «Җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килү, аларны файдалану, зарарсызландыру, ташу һәм урнаштыру турында мәгълүматлар» федераль дәүләт статистик күзәтчелеге формалары күчермәләре №2-ТП (калдыклар);<br>«Әйләнә-тирә мохитне саклауга һәм табигый ресурслардан нәтиҗәле файдалануга юнәлтелгән төп капиталга инвестицияләр турында мәгълүматлар» федераль дәүләт статистик күзәтчелеге формасы күчермәләре №18-кс;<br>куркыныч калдыкларның паспортлары;<br>калдыкларны исәпкә алу журналы |
| | 1.17. Урнаштыру (ҖКК күмү) өчен рөхсәтләр булуы, урнаштырылган калдыкларның суммар | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль | калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проекты;<br>ҖКК урнаштыру өчен лимитлар;<br>бер предприятиенеке булган |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | күләменең аларның барлыкка килүенә туры килүе, (куллану, саклау (туплау), тапшыруны исәпкә алып) | законның 18 ст.;<br>РФ Табигать министрлыгының 2010 елның 25 февралендәге 50 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативларын һәм аларны урнаштыру лимитларын эшләү һәм раслау тәртибе | калдыкларны икенче бер предприятие полигонына урнаштыру (күмү) турында шартнамә (калдыкларны экологик яктан куркынычсыз итеп төргәкләү, транспортлау, төяп озату һәм бушату буенча якларның бурычларын һәм җаваплылыкларын билгели) |
| | 1.18. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләүләр кертү | «Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 16 ст.;<br>«Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 23 ст. | түләү йөкләмәләре күчермәләре;<br>әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен квартал саен түләү исәпләмәләре |
| | 1.19. Билгеләнгән таләпләр нигезендә эш урыннарында ЖКК җыйганда, туплаганда, | ТР Табигать министрлыгы тарафыннан 1994 елның 12 июлендә расланган Җитештерү һәм | җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, урнаштыру (күмү) тәртибен, экологик һәм җитештерү |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | кулланганда, зарарсызландырганда, урнаштырганда (күмгәндә) тәртипне, экологик һәм житештерү куркынычсызлыгын, җаваплылыкны билгели торган күрсәтмәләрнең булуы һәм аларны үтәү | куллану калдыкларын урнаштыруга (күмүгә) рөхсәт бирү тәртибе турында күрсәтмә ОНД 1-94 | куркынычсызлыгын, җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, урнаштыру (күмү) вакытында җаваплылык билгели торган күрсәтмәләр |
| | 1.20. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү контролен оештыру һәм гамәлгә ашыру | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 26 ст. | калдыклар белән эш итү өлкәсендә Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы белән килештерелгән җитештерү контролен гамәлгә ашыру тәртибе |
| | | Санитар кагыйдәләрнең үтәлешенә һәм санитария-эпидемияләргә каршы (профилактик) чаралар үтәлешенә производство контролен оештыру һәм үткәрү. 1.1.1058-01;<br>ТР Табигать министрлыгы тарафыннан 1994 елның 12 июлендә расланган Җитештерү һәм | җитештерү контроле программасы (планы);<br>гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек нигезендә яшәү тирәлеге факторларын тикшерүнең санитар кагыйдәләре, методлары һәм методикалары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | куллану калдыкларын урнаштыруга (күмүгә) рөхсәт бирү тәртибе турында күрсәтмә ОНД 1-94 | |
| | 1.21. Лаборатория контролен гамәлгә ашыру | РФ Баш дәүләт санитар табибы тарафыннан 2003 елның 26 июнендә расланган Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүгә җитештерү контроле буенча чаралар комплексына керүче лаборатор тикшеренүләрне үткәрүне оештыру һәм аның күләме буенча 17ФЦ/3329 номерлы методик киңәшләр | җитештерү контроле нәтиҗәләре (шул исәптән лаборатор тикшеренүләр);<br>Санэпиднадзор органнары тарафыннан предприятиене тикшерү актлары;<br>ҖКК өлешендә күрсәтмәләр |
| | шул исәптән, лаборатор тикшеренүләрне, пробаларны сайлап алу нокталарын, лаборатор тикшеренүләрнең төрен һәм аларның ешлыгын | | санитар-эпидемиология хезмәте мәгълүматы:<br>- гамәлдәге санитар кагыйдәләр, гигиена нормативлары, кеше яшәү тирәлеге факторларын контрольдә тоту методлары һәм методикалары турында, алар объектта булырга тиеш; |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | оештыру максатка ярашлы булган химик матдәләр, биологик, физик һәм башка факторлар исемлеге өлешендә санитар-эпидемиология хезмәте мәгълүматы белән җитештерү контроле программасын (планын) чагыштыру | | - пробаларны сайлап алу нокталарын, лаборатор тикшеренүләрнең төрен һәм аларның ешлыгын күрсәтеп, лаборатор тикшеренүләрне оештыру максатка ярашлы булган химик матдәләр, биологик, физик һәм башка факторлар исемлеге; - санитар-эпидемиология хезмәте белән килештерелгән җитештерү контроле программасы (планы) |
| | 1.22. Тикшерелә торган объект балансында булган каты көнкүреш калдыклары өчен полигон торышының, санкцияләнгән чүплек урынының билгеләнгән таләпләргә туры килүе | | |
| | 1.23. Калдыкларны урнаштыру объектларының дәүләт реестрында урнаштыру объектын теркәү турында таныклык булуы | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 12 ст. 7 п. | калдыкларны урнаштыру объектларының дәүләт реестрында урнаштыру объектын теркәү турында таныклык күчермәсе |
| | 1.24. Полигонда ҖКК урнаштыруның | ГОСТ 12.1007-76 «Зарарлы матдәләр. | агулы сәнәгать калдыкларының төренә карап утильләштерү, |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | билгеләнгән таләпләргә туры килүе | Классификация һәм гомуми куркынычсызлык таләпләре» | зарарсызландыру һәм күмү процессларын оештыру буенча технологик регламентлар, технологик схемалар, методик киңәшләр |
| | 1.25. Агулы каты сәнәгать калдыкларын зарарсызландыру һәм күмү полигоны җиһазларының һәм аның эксплуатацияләүнең туры килүе | СНиП 2.01.28-85 «Агулы сәнәгать калдыкларын зарарсызландыру һәм күмү полигоннары. Проектлау буенча төп нигезләмәләр»; ГОСТ 30772-2001 «Ресурсларны саклау. Калдыклар белән эш итү. Терминнар һәм билгеләмәләр» | |
| | 1.26. Полигонны эксплуатацияләүнең билгеләнгән санитар таләпләргә туры килүе | РФ Баш дәүләт санитар табибы тарафыннан 2003 елның 26 июнендә расланган Җитештерү һәм куллану калдыклары белән эш итүгә җитештерү контроле буенча чаралар комплексына керүче лаборатор тикшеренүләрне үткәрүне оештыру һәм аның күләме | тикшерелә торган объект балансында булган каты көнкүреш калдыклары полигонын, санкцияләнгән чүплек урыннарын лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | буенча 17ФЦ/3329 номерлы методик киңәшләр | |
| | шул исәптән полигонның санитар торышының 2001 елның 30 маендагы СП 2.1.7.1038-01 2.3, 2.4, 2.8, 2.10, 3.2, 3.4, 3.6, 3.8-3.10, 4.1-4.7, 5.1, 5.3-5.5, 5.7, 6.1-6.9, 8.1-8.5 пунктлары таләпләренә туры килүе | СП 2.1.7.1038-01 «Каты көнкүреш калдыклары полигоннарын төзүгә һәм карап тотуга гигиена таләпләре» | полигонның эш регламенты һәм эш режимы;<br>көнкүреш калдыкларын кабул итү буенча аңлатма;<br>килә торган калдыкларның составын контрольдә тоту нәтиҗәләре;<br>керә торган калдыкларны исәпкә алу журналы (исәп буенча документлар) (тәүлек әйләнәсе) ;<br>полигонның эшләүче өлешендә калдыкларны бүлүне тикшерү нәтиҗәләре;<br>калдыклар изоляциясе буенча технологик цикл тасвирламасы;<br>Роспотребнадзорның территориаль үзәге белән килештерелгән полигонга кабул ителә торган калдыклар исемлеге;<br>Роспотребнадзор органнары тарафыннан полигонны тикшерү актлары;<br>ҖКК өлешендә күрсәтмәләр;<br>Роспотребнадзор тарафыннан бирелгән каты көнкүреш калдыклары полигоннарын урнаштыру өчен сайлап алынган кишәрлекнең гигиеник таләпләренә туры килүе турында санитар- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | эпидемиологик бәяләмә;<br>калдыклар кабул итү буенча контроль нәтиҗәләре;<br>җитештерү контроле программасы (планы), түбәндәгеләрне күздә тота:<br>полигонның тискәре йогынтысы зонасында җир асты һәм өслек су объектларының, атмосфера һавасының, туфракларның, тавыш дәрәҗәсенең торышын контрольдә тоту;<br>территориаль гигиена һәм эпидемиология органы белән килештерелгән һәм билгеләнгән тәртиптә расланган калдыклар санын билгели торган документ;<br>территориаль гигиена һәм эпидемиология органы тарафыннан бирелгән сәнәгать калдыкларын һәм каты көнкүреш калдыкларын уртак саклау һәм күмү турында санитар-эпидемиологик бәяләмә;<br>кабул ителә торган калдыкларны исәпкә алу документлары |
| 2. Куркыныч калдыкларны транспортлау | 2.1. I-IV класслы куркыныч калдыклар паспортының булуы | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ | куркыныч калдыкларның паспортлары |

| | | | |
|---|---|---|---|
| таләпләрен һәм кагыйдәләрен үтәү | | номерлы федераль законның 16 ст. | |
| | 2.2. Махсус җиһазландырылган һәм махсус билгеләр белән тәэмин ителгән транспорт чаралары булу | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 16 ст.;<br>Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 1995 елның 8 августындагы 73 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль транспортында куркыныч йөкләрне алып бару кагыйдәләре | |
| | 2.3. Шул исәптән түбәндәгеләрнең булуы һәм дөреслеге:<br>- йөкнең куркынычлылык классын билгеләү өчен транспорт чарасына билгеләнә торган мәгълүмат таблицасы;<br>- куркыныч | Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 1995 елның 8 августындагы 73 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль транспортында куркыныч йөкләрне алып бару кагыйдәләре | Йөкнең куркыныч классын билгеләү өчен транспорт чарасына урнаштырыла торган мәгълүмат таблицасы;<br>- куркыныч турында мәгълүмат системасының авария карточкасы (аварияләрне яки инцидентларны һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү чараларын билгеләү өчен);<br>куркынычлылык турында мәгълүмат системасының мәгълүмат карточкасы |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | турында мәгълүмат системасының авария хәлендәге карточкалары (аварияләрне яки инцидентларны һәм аларның нәтиҗәләрен бетерү чараларын билгеләү өчен);<br>- куркынычлылык турында мәгълүмат картасы системасы мәгълүматы | | |
| | 2.4. I-IV класслы калдыкларны транспорт чараларында транспортлауга карата куркынычсызлык таләпләрен үтәү, шул исәптән: | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 16 ст.;<br>Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 1995 елның 8 августындагы 73 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль транспортында куркыныч йөкләрне алып бару кагыйдәләре | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 2.4.1. Куркынычлылык билгеләрен үз эченә алган маркировкалар булуы | ГОСТ 1943-88 «Куркыныч йөкләр. Классификация һәм маркировкалау»; ГОСТ 14192-96 «Йөкләрне маркировкалау» | |
| | 2.5. Куркыныч йөкләрне төрүгә карата таләпләрне үтәү | Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 1995 елның 8 августындагы 73 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль транспортында куркыныч йөкләрне алып бару кагыйдәләре; ГОСТ 26319-84 «Куркыныч йөкләр. Төргәкләү» | |
| | 2.6. I-IV класслы куркыныч калдыкларны транспортлау һәм тапшыру өчен документлар булуы | «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында» 1998 елның 24 июнендәге 89-ФЗ номерлы федераль законның 16 ст. | |
| | 2.7. Куркыныч йөкләр ташуга транспорт | Россия Федерациясе Транспорт | транспорт чарасын транспорт чарасын теркәү урыны буенча Россия ЭЭМ |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | чарасын кертү турында таныклык булуы | министрлыгының 1995 елның 8 августындагы 73 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль транспортында куркыныч йөкләрне алып бару кагыйдәләре | ДАИ бүлекчәсе тарафыннан бирелгән куркыныч йөкләрне ташуга кертү турында таныклык |
| | 2.8. Транспорт документларының булуы һәм дөреслеге:<br>куркыныч йөк ташуның маршрут бланкы;<br>куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларын йөртүчеләрне әзерләү турында таныклык | Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 1995 елның 8 августындагы 73 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль транспортында куркыныч йөкләрне алып бару кагыйдәләре | рөхсәтнең гамәлдә булу чорын күрсәтеп, «аеруча куркыныч йөкне» (өске уң почмакта) транспортлауга рөхсәт турында тамгалап, ташу маршруты (бланкта);<br>куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларын йөртүчеләрне әзерләү турында таныклык;<br>куркыныч йөкләр ташучы транспорт чараларын йөртүгә рөхсәт турында таныклык |
| | 2.9. Куркыныч йөк ташуга шартнамә булуы | Россия Федерациясе Транспорт министрлыгының 1995 елның 8 августындагы 73 номерлы боерыгы белән расланган Автомобиль транспортында куркыныч йөкләрне алып бару | куркыныч йөк ташу буенча шартнамә |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | кагыйдәләре | |

4. Тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар

Дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документларның исемлеге, шулай ук мондый документларның рәвешләрен раслый торган норматив хокукый актлар 4 нче таблицада китерелде.

4 нче таблица. Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге

| Тикшерү үткәрү өчен күрсәтелә торган документ | Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|
| Предприятие эшчәнлеген билгели торган документлар | |
| 1. Эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлау турында хәбәр (Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр исемлеге нигезендә эшләр һәм хезмәт күрсәтүләрне башкаручы юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар өчен) | «Эшкуарлык эшчәнлегенең аерым төрләрен гамәлгә ашыра башлауның хәбәр итү тәртибе турында» 2009 елның 16 июлендәге 584 номерлы РФ Хөкүмәте карары |
| 2. Җитештерү структурасы | - |
| 3. Аерым технологик процесслар буенча барлыкка килә торган калдыклар номенклатурасы һәм күләме | - |
| 4. Калдыклар барлыкка килүне чагылдыра торган предприятие буенча тулаем баланс схемалары яки матди агымнар схемалары | - |
| 5. Җитештерү барышында калдыклар барлыкка килә торган продукциянең барлык төрләренә технологик регламентлар | - |
| 6. Продукция берәмлегенә калдыклар барлыкка килүнең тармак нормативлары | - |
| 7. Стандартлар, продукциягә техник шартлар | - |
| 8. Яңа продукциягә стандартлар, техник шартлар | |
| 9. Яңа продукция җитештерүгә технологик регламентлар | - |
| 10. Полигонның регламенты һәм эш режимы | |

| | |
|---|---|
| 11. Җитештерү территориясендә сәнәгый калдыкларны җыю һәм туплау шартларын үз эченә алган техник регламент (проект, предприятие паспорты, ТУ, күрсәтмәләр) | - |
| 12. Агулы сәнәгать калдыкларының төренә карап утильләштерү, зарарсызландыру һәм күмү процессларын оештыру буенча технологик регламентлар, технологик схемалар, методик киңәшләр | - |
| 13. Полигонда калдыкларны изоляцияләү буенча технологик цикл тасвирламасы | - |
| Хокук билгели торган, лицензия, рөхсәт документлары һәм шартнамәләр | |
| 14. Җир кишәрлегенә ия булу яки аннан файдалану хокукы өчен документлар | - |
| 15. Куркыныч калдыкларны җыю, куллану, йогышсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензия (шул исәптән куркыныч калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, транспортлау һәм урнаштыру эшчәнлеге составында куркыныч калдыкларның исемлеге һәм эш төрләре) | РФ Хөкүмәтенең «Лицензиянең бер төр рәвешен раслау турында» 2011 елның 6 октябрендәге 826 номерлы карары |
| 16. Куркыныч калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, ташу, урнаштыру эшчәнлегенә бирелгән лицензияләр реестрыннан өземтә | 2007 елның 10 декабрендәге 848 номерлы Ростехнадзор боерыгы белән расланган Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең куркыныч калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, ташу, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты |
| 17. Куркыныч калдыкларны җыю, куллану, йогышсызландыру, ташу, урнаштыру буенча эшчәнлекне гамәлгә ашырганда дәгъва кылучы (лицензиат) тарафыннан лицензия таләпләрен һәм шартларны үтәү мөмкинлеген тикшерү актлары (кушымта итеп бирелә торган документлар белән:<br>- продукция үрнәкләрен (пробаларын) сайлап алу, әйләнә-тирә мохит объектларын | 2007 елның 10 декабрендәге 848 номерлы Ростехнадзор боерыгы белән расланган Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең куркыныч калдыкларны җыю, куллану, зарарсызландыру, ташу, |

| | |
|---|---|
| тикшерү турында актлар;<br>- үткәрелгән тикшеренүләр (сынаулар) һәм экспертизалар беркетмәләре (бәяләмәләре);<br>- зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнә торган дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнарының вазыйфаи затларының, хезмәткәрләрнең аңлатмалары;<br>- контрольлек чарасы нәтиҗәләренә бәйле башка документлар); | урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламенты |
| 18. Лицензияләнә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен кирәкле техник нормаларга һәм таләпләргә туры килә торган җитештерү бүлмәләренең, калдыкларны урнаштыру объектларының, җиһазларның, транспорт чараларының булуын раслаучы документлар | Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 3 октябрендәге 1062 номерлы карары белән расланган I-IV класслы куркынычлык калдыкларын җыю, транспортлау, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, урнаштыру эшчәнлеген лицензияләү турында нигезләмә |
| 19. Куркыныч калдыклар белән эш итү эшчәнлегенә кертелгән затлар өчен куркыныч калдыклар белән эшләү хокукына таныклыклар (сертификатлар) | - |
| 20. Калдыклар урнаштыру һәм зарарсызландыру белән бәйле объектларның проект документларына дәүләт экологик экспертизасының уңай бәяләмәсе (2008 елның 30 декабрендәге 309-ФЗ номерлы федераль закон үз көченә кергәнче файдалануга тапшырылган яки төзелешенә рөхсәт бирелгән объектлардан тыш) | - |
| 21. Предприятие лабораториясен аккредитацияләү турында аттестат (лаборатория булганда) | - |
| 22. Бер предприятиенеке булган калдыкларны икенче бер предприятие полигонына урнаштыру (күмү) турында шартнамә (калдыкларны экологик яктан куркынычсыз итеп төргәкләү, транспортлау, төяп озату һәм бушату буенча якларның бурычларын һәм җаваплылыкларын билгели) | - |
| 23. Калдыкларны урнаштыру объектларының дәүләт реестрында урнаштыру | - |

| | |
|---|---|
| объектын теркәү турында таныклык | |
| 24. Транспорт чарасын транспорт чарасын теркәү урыны буенча Россия ЭЭМ ДАИ бүлекчәсе тарафыннан бирелгән куркыныч йөкләрне ташуга кертү турында таныклык | - |
| 25. Йөк җибәрүчегә (йөк алучыга) аның урнашу урыны буенча Эчке эшләр органнары тарафыннан бирелгән «аеруча куркыныч йөкләрне» ташуга рөхсәт | - |
| 26. Куркыныч йөкләрне ташу өчен файдаланыла торган транспорт чараларын йөртүчеләрне әзерләү турында таныклык | - |
| 27. Куркыныч йөк ташу буенча шартнамә | - |
| 28. Рөхсәтнең гамәлдә булу чорын күрсәтеп, «аеруча куркыныч йөкне» (өске уң почмакта) транспортлауга рөхсәт турында тамгалап, ташу маршруты (бланкта) | - |
| Предприятиенең экологик хезмәтен оештыру буенча документлар | |
| 29. Җитештерү контролен махсус төзелгән хезмәткә яисә билгеләнгән җаваплы затка йөкләү турында юридик зат боерыгы (күрсәтмәсе) | - |
| 30. Махсус төзелгән (экологик) хезмәт турында нигезләмә | - |
| 31. Экология хезмәте хезмәткәрләренең (экологның) вазыйфаи күрсәтмәләре | - |
| 32. Экология хезмәте хезмәткәрләренең (экологның) зарури һөнәри әзерлеген яисә яңадан әзерләнүен раслаучы документлар | - |
| Җитештерүдә экологик тикшерүенең оештыру документлары һәм аны үткәрү буенча документлар | |
| 33. Табигатьне саклау чаралары планы, еллык һәм перспективалы | - |
| 34. Табигатьне саклау чаралары планын үтәү турында хисап | - |
| 35. Санитар-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар планы | - |
| 36. Санитария-эпидемиягә каршы (профилактик) чаралар планын үтәү турында хисап | - |
| 37. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә җитештерү контролен оештыру һәм уздыру тәртибе (предприятиенең (оешманың) экологик контроле турында юридик зат тарафыннан | - |

| | |
|---|---|
| расланган, ТР Экология министрлыгы тарафыннан килештерелгән нигезләмә составында) | |
| 38. Предприятиедә җитештерү контролен үткәрү планы-графигы | - |
| 39. Җитештерү контроле нәтиҗәләре | - |
| 40. Сәнәгать мәйданчыклары территорияләре туфракларына, территорияләренә җитештерү контроле нәтиҗәләре | - |
| 41. Продукциянең яңа төрләре һәм яңа технологияләр йогынтысын ала торган яшәү тирәлеге факторларын тикшереп тору методлары | - |
| 42. Тикшерелә торган объект балансында булган каты көнкүреш калдыклары полигонын, санкцияләнгән чүплек урыннарын лаборатория тикшеренүләре нәтиҗәләре | - |
| 43. Полигонга керә торган калдыкларның составын контрольдә тоту нәтиҗәләре | - |
| 44. Җир асты һәм өслек су объектларының, атмосфера һавасының, туфракларның, тавыш дәрәҗәләренең торышына җитештерү контроле программасы (планы) | - |
| Норматив документлар | |
| 45. Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проекты | Россия Табигать министрлыгының 349 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр |
| 46. Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыру лимитлары проектын карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә (җитештерү процессының, кулланыла торган чималның һәм барлыкка килә торган калдыклар турында техник хисапның үзгәрешсезлеге турында техник хисап) (калдыклар барлыкка килү нормативлары проекты һәм аларны урнаштыру лимитлары проектының белешмәләрен раслау) | Россия Табигать министрлыгының 349 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр |
| 47. Җитештерү процессының, | Россия Табигать |

| | |
|---|---|
| файдаланыла торган чималның һәм барлыкка килә торган калдыкларның үзгәрмәве турында техник хисап ________ башлап ________ кадәрге чорга | министрлыгының 349 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр |
| 48. Җитештерү процессының, кулланыла торган чимал һәм барлыкка килә торган калдыклар турында техник хисапны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә | Россия Табигать министрлыгының 349 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр |
| 49. Калдыкларны урнаштыру лимитлары, шул исәптән:<br>- калдыкларны урнаштыру объектларында урнаштыру;<br>- калдыклар урнаштыру объектларында урнашкан калдыкларның исемлеге һәм саны;<br>- калдыкларны урнаштыру объектларында урнаштыру лимиты;<br>- предприятие территориясендә вакытлыча туплана торган калдыкларның исемлеге һәм саны | Россия Табигать министрлыгының 349 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр |
| 50. Калдыкларны урнаштыру лимитларын юкка чыгару турында акт (булган очракта) | Россия Табигать министрлыгының 349 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар барлыкка килү нормативлары һәм аларны урнаштыруга лимитлар проектларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр |
| 51. Куркыныч калдыкларның паспортлары | РФ Хөкүмәтенең 712 номерлы карары |
| Беренчел исәп документлары | |
| 52. Технологик процесс параметрларын алып бару журналы | - |
| 53. Предприятиедә барлыкка килә торган калдыклар исемлеге, калдыкларның федераль классификация каталогы нигезендә | - |
| 54. Роспотребнадзорның территориаль үзәге белән килештерелгән полигонга кабул | - |

| | |
|---|---|
| ителә торган калдыклар исемлеге | |
| 55. Калдыклар хәрәкәтен раслаучы документлар:<br>- керем-чыгым документлары;<br>- карточкалар һәм склад исәбе;<br>- алып чыгу өчен документлар | - |
| 56. Калдыкларны инвентаризацияләү буенча хисап | - |
| 57. Калдыкларны исәпкә алу мәгълүматлары | РФ Табигать министрлыгының 2011 елның 1 сентябрендәге 721 номерлы боерыгы белән расланган Калдыклар белән эш итү өлкәсендә исәпкә алу тәртибе |
| 58. Полигонга керә торган калдыкларны исәпкә алу журналы (исәпкә алу документлары) (тәүлек әйләнәсе); | - |
| Дәүләт күзәтчелеге нәтиҗәләре буенча документлар | |
| Дәүләт экология күзәтчелеге | |
| 59. ҖКК белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашырганда предприятиегә уздырылган алдагы тикшерүләр нәтиҗәләре буенча документлар | Җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килү һәм алар белән эш итүгә бәйле хуҗалык һәм башка эшчәнлеккә дәүләт контролен үткәрү һәм әйләнә-тирә табигать тирәлеген алардан саклау буенча методик күрсәтмәләр, ТР Табигать министрлыгының 1994 елның 1 ноябрендә расланган МУ-1-94 |
| 60. ҖКК белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелегенең алдагы тикшерү нәтиҗәләре буенча актлар һәм күрсәтмәләр | - |
| 61. ҖКК белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелегенең алдагы тикшерү нәтиҗәләре буенча административ хокук бозулар турында беркетмәләр (карарлар) | - |
| 62. ҖКК белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелегенең алдагы тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган табигать саклау законнарын бозуларны бетерү буенча чаралар планы һәм предприятие буенча боерыклар | - |
| 63. ҖКК белән эш итү өлкәсендә дәүләт күзәтчелегенең алдагы тикшерү нәтиҗәсендә ачыкланган табигать саклау законнарын | - |

| | |
|---|---|
| бозуларны бетерү буенча чаралар үтәлеше турында хисаплар | |
| 64. Экологик экспертиза тәкъдимнәрен үтәү турында хисап | - |
| Санитар-эпидемиологик күзәтчелек | |
| 65. Роспотребнадзор органнары тарафыннан предприятиене тикшерү актлары | - |
| 66. Санитар-эпидемиология хезмәте мәгълүматы:<br>- гамәлдәге санитар кагыйдәләр, гигиена нормативлары, кеше яшәү тирәлеге факторларын контрольдә тоту методлары һәм методикалары турында, алар объектта булырга тиеш;<br>- пробаларны сайлап алу нокталарын, лаборатор тикшеренүләрнең төрен һәм аларның ешлыгын күрсәтеп, лаборатор тикшеренүләрне оештыру максатка ярашлы булган химик матдәләр, биологик, физик һәм башка факторлар исемлеге;<br>- санитар-эпидемиология хезмәте белән килештерелгән җитештерү контроле программасы (планы) | - |
| 67. Дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның карарлары, күрсәтмәләре һәм санитар-эпидемиологик бәяләмәләр | - |
| 68. Дәүләт санитар-эпидемиология күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларның карарлары, күрсәтмәләре һәм санитар-эпидемиологик бәяләмәләренең үтәлеше турында хисаплар | - |
| 69. Роспотребнадзор органнары тарафыннан полигонны тикшерү актлары | - |
| 70. Полигонны Роспотребнадзор органнары тарафыннан ҖКК өлешендә тикшерү нәтиҗәләре буенча күрсәтмәләр | - |
| 71. Роспотребнадзор тарафыннан бирелгән каты көнкүреш калдыклары полигоннарын урнаштыру өчен сайлап алынган кишәрлекнең гигиена таләпләренә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә | - |
| 72. Дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вазыйфаи | - |

| | |
|---|---|
| затларның авария хәлләренә, җитештерү тукталышларына, халыкның санитар-эпидемиологик иминлегенә куркыныч тудыручы технологик процессларны бозуга бәйле рәвештә эшләнгән карарлары, күрсәтмәләре һәм санитар-эпидемиологик бәяләмәләре (аларның үтәлеше турында хисаплар) | |
| 73. Биологик матдәләр, биологик һәм микробиологик организмнар һәм аларның токсиннары белән эшләү шартларының санитар кагыйдәләргә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә (мондый эшләр булган очракта) | - |
| 74. Кешегә йогынты ясауның физик факторлары чыганаклары белән эшләү шартларының санитария кагыйдәләренә туры килүе турында санитар-эпидемиологик бәяләмә (мондый машиналар, механизмнар, җайланмалар, җиһазлар һәм аппаратлар кулланылган очракта) | - |
| 75. Роспотребнадзор тарафыннан бирелгән сәнәгать калдыкларын һәм каты көнкүреш калдыкларын уртак саклау һәм күмү турында санитар-эпидемиологик бәяләмә | - |
| Дәүләт статистика хисаплылыгы | |
| 76. «Җитештерү һәм куллану калдыклары барлыкка килү, аларны файдалану, зарарсызландыру, ташу һәм урнаштыру турында мәгълүматлар» федераль дәүләт статистик күзәтчелеге формалары №2-ТП (калдыклар) | «Җитештерү һәм куллану калдыкларына федераль статистика күзәтчелеген оештыру өчен статистик инструментарийны раслау турында» 2011 елның 28 гыйнварындагы 17 номерлы Росстат боерыгы |
| Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләү | |
| 77. Калдыкларны урнаштыру нәтиҗәсендә әйләнә-тирәлеккә тискәре йогынты өчен түләү кертү буенча түләү йөкләмәләре күчермәләре | - |
| 78. Әйләнә-тирә мохиткә тискәре йогынты өчен түләү кертү турында квартал саен декларацияләр | - |
| Норматив-хокукый документлар | |
| 79. Гамәлгә ашырыла торган эшчәнлек нигезендә яшәү тирәлеге факторларын | - |

| | |
|---|---|
| контрольдә тоту алымнары һәм методикалары рәсми басылып чыккан санитар кагыйдәләр, методлар һәм методикалар | |
| 80. Кеше өчен куркынычсыз хезмәт шартларын тәэмин итүгә, җитештерү, җәмәгать биналарыннан, биналардан, корылмалардан, җайланмалардан һәм транспорттан файдалануга карата таләпләрне билгеләүче Россия Федерациясенең санитария кагыйдәләре һәм башка норматив хокукый актлары. | - |
| 81. Туфракка, сәнәгать мәйданчыклары территорияләрен карап тотуга карата санитар-эпидемиологик таләпләрне билгеләүче норматив актлар | - |
| 82. Җитештерү һәм куллану калдыкларын җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, урнаштыру (күмү) тәртибен, экологик һәм җитештерү куркынычсызлыгын, җыю, туплау, куллану, зарарсызландыру, урнаштыру (күмү) вакытында җаваплылык билгели торган күрсәтмәләр | - |

5. Административ процедураларның (гамәлләрнең) составы, эзлеклелеге һәм аларны үтәү вакытлары, аларны үтәү тәртибенә карата таләпләр, шул исәптән административ процедураларны (гамәлләрне) электрон формада да үтәү үзенчәлекләре

Дәүләт күзәтчелеге юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны планлы (документар һәм күчмә) һәм планнан тыш (документар һәм күчмә) тикшерүләр рәвешендә гамәлгә ашырыла.

Әлеге Регламент түбәндәге административ процедураларның үтәлүен күздә тота:

юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү уздыру;

юридик затка, шәхси эшкуарга планлы күчмә тикшерү уздыру.

юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү уздыру;

юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү;

Дәүләт функциясен үтәүнең блок-схемасы шушы Регламентка 3 нче кушымтада китерелә.

Россия Федерациясе законнарында дәүләт функциясен үтәүне туктатып тору каралмаган.

5.1. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасы

5.1.1. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасын башлап җибәрү өчен тиешле юридик затны, шәхси эшкуарны еллык Планга кертү нигез булып тора. Лицензиатка карата планлы тикшерүне еллык Планга кертү әлеге Регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

«Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү уздыру» административ процедурасы түбәндәге гамәлләр тәртибе нигезендә гамәлгә ашырыла:

планлы документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү турында карар кабул итү;

Министр (министр урынбасары) боерыгын (күрсәтмәләрен) рәсмиләштерү;

юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү үткәреләчәге турында хәбәр итү;

планлы документар тикшерү уздыру;

планлы документар тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.1.2. Тикшерүләр планы нигезендә ТР ЭТРМ Дәүләт экологик күзәтчелек инспекциясе башлыгы (ТР ЭТРМ территориаль идарәсе башлыгы):

ТР ЭТРМ вазыйфаи затлары арасыннан җаваплы башкаручыларны билгели, шул ук вакытта карар кабул итү таләбе булып вазыйфаи затның (алга таба – җаваплы башкаручы) юридик затка, шәхси эшкуарга әлеге Регламентның 2.5 пункты нигезендә тикшерүләр уздыруга вәкаләтләре булуы тора;

тикшерү уздырыла торган юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларның аффилирланган затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын тикшерүгә җәлеп итә.

Үтәлү вакыты: тикшерү башланганчы биш эш көне эчендә йә еллык планны төзегәннән соң.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

5.1.3. Җаваплы башкаручы:

юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү уздыру турында министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) проектын, әлеге Регламентның 4 нче кушымтасы нигезендә җаваплы башкаручыларга, ТР ЭТРМ Үзәк махсуслаштырылган аналитик контроль инспекциясе белгечләренә юридик затның (шәхси эшкуарның) объектында (объектларында) күзәтчелек чараларын үткәрү буенча план-бирем әзерли;

боерык (күрсәтмә) проектын имзалау өчен министрга (министр урынбасарына) юллый.

Үтәлү вакыты: тикшерү уздырыла башлаганчы өч эш көне эчендә, юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү үткәрү турында хәбәрнамәгә кирәкле вакытны исәпкә алмыйча, хәбәр итү ысулыннан чыгып исәпләнә).

Эш нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган тикшерү үткәрү турында боерык (күрсәтмә).

5.1.4. Җаваплы башкаручы юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) күчермәсен, тапшыру турында уведомление белән яки башка мөмкин булган ысул белән (факсимиль элемтә, электрон почта аша, алу турында тамгасы белән бергә) заказлы почта аша тикшерү үткәрү турында боерык (күрсәтмәнең) күчермәсен җибәрү юлы белән хәбәр итә.

Үтәлү вакыты: тикшерү башланганчы өч эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: тикшерү үткәрү турында юридик зат, шәхси эшкуар адресына җибәрелгән министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) күчермәсе.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларын планлы тикшерү үткәргән очракта, җаваплы башкаручы, тикшерү башланганчы өч эш көне эчендә, планлы тикшерү үткәргәндә катнашу яки аның вәкиленең булу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, үз-үзен көйләүче оешмага хәбәр җибәрә.

Юридик зат, шәхси эшкуар ун эш көне дәвамында министрның (министр урынбасарының) тикшерү үткәрү турындагы боерыгының (күрсәтмәсенең) күчермәсендә күрсәтелгән документларны мөһер (булган очракта) һәм шәхси эшкуарның, аның вәкаләтле вәкиленең, юридик зат җитәкчесенең, аның башка вазыйфаи затының имзасы белән таныкланган күчермәләр рәвешендә ТР ЭТРМ җибәрергә бурычлы.

Әгәр Россия Федерациясе законнарында башкача каралмаса, ТР ЭТРМ тапшырыла торган документларның күчермәләрен нотариаль яктан таныклауны таләп итү рөхсәт ителми.

Юридик зат, шәхси эшкуар мөрәҗәгатьтә күрсәтелгән документларны Россия Федерациясе Хөкүмәте билгели торган тәртиптә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документлар рәвешендә дә тапшырырга хокуклы.

5.1.5. ТР ЭТРМ булган документлардагы мәгълүматлар һәм юридик зат, шәхси эшкуар биргән документлардагы мәгълүматлар нигезендә җаваплы башкаручы:

мәгълүматларның дөреслегенә бәя бирә;

документларда булган белешмәләрне юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенә билгеләнгән зарури таләпләргә туры килүе предметына бәя бирә;

Әгәр документлардагы белешмәләрнең төгәл булу-булмавында нигезле шик барлыкка килсә, яисә әлеге белешмәләр юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан зарури таләпләрнең үтәлгәнлеген бәяләргә ирек бирмәсә, әгәр ТР ЭТРМ тапшырылган һәм аның карамагында булган документларда хаталар ачыкланса һәм (яисә) каршылыклар, белешмәләрнең туры килмәү очраклары булса, җаваплы башкаручы:

белешмәләрне бәяләү нәтиҗәләре турында мәгълүмат һәм дәлилләнгән гариза белән юридик зат, шәхси эшкуар адресына хат әзерли һәм ун эш көне дәвамында язма рәвештә кирәкле аңлатмалар йә документларны карау өчен кирәкле башка аңлатмалар бирү таләбен куя;

Кул куйганнан соң хатны заказлы почта юлламасы белән җибәрә, тапшыру турында хәбәрнамә белән яисә алу турында тамга белән махсус җибәрә.

Үтәлү вакыты: тикшерү башланган көннән алып биш эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: юридик зат, шәхси эшкуар адресына юлланган (җибәрелгән) документларны тапшыру таләбе белән хат (мотивлаштырылган гариза).

5.1.6. Күчмә тикшерү әлеге Регламентның 5.2 пунктында китерелгән тәртип нигезендә башкарыла.

Күчмә тикшерү үткәрү турындагы карарны министр (министр урынбасары) кабул итә.

Күчмә тикшерү уздыру зарурлыгы турында карар кабул итү өчен юридик, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырылган аңлатмаларны һәм (яисә) документларны карау барышында ачыкланган, күчмә тикшерү уздыру өчен нигез булып хезмәт итүче зарури таләпләрнең бозылу билгеләре төп критерий булып тора.

Үтәү вакыты: аңлатмаларны алганнан соң өч эш көне дәвамында.

Эш нәтиҗәсе: җаваплы башкаручы тарафыннан карап тикшерелгән аңлатмалар һәм (яки) документлар; кирәк булганда, күчмә тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) проекты.

5.1.7. Планлы документар тикшерү нәтиҗәләре буенча җаваплы башкаручы юридик затны, шәхси эшкуарны тикшерү буенча ике нөсхәдә ТР ЭТРМ актын төзи.

Контрольлек чаралары нәтиҗәсендә зарури таләпләрне бозу очраклары ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы законнарны үтәүне (ачыкланган бозулар нәтиҗәсендә китерелгән зыянны каплауга) тәэмин итүгә юнәлдерелгән түбәндәге вәкаләтләрнең тормышка ашырылуын гамәлгә ашыра:

тикшерү актында ачыкланган бозуларның барлык очракларын да терки;

аларны бетерү срокларын күрсәтеп, ачыкланган бозуларны бетерү турында һәм (яки) кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләт яки муниципаль мөлкәткә зыян салынуны булдырмый калу, табигый һәм техноген рәвештәге гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүен кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны уздыру турында үтәү өчен зарури булган, тикшерү актына кушымта булып торган күрсәтмәләрне (һәр бозу очрагы буенча аерым күрсәтмә) бирә (күрсәтмә рәвеше әлеге Регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән) һәм әлеге күрсәтмәләрнең әлеге Регламентта каралган тәртиптә билгеләнгән чорларда үтәлүен тикшереп тора;

Администартив хокук бозулар турында РФ кодексының 8.1 ст., 8.2 ст., 8.4 ст., 8.5 ст., 8.6 ст., 8.19 ст., 8.31 ст. 2, 3 өл., 8.41 ст., 19.4 ст. 1 өл., 19.5 ст. 1 өл., 19.6 ст., 19.7 ст., 19.33 ст. каралган административ хокук бозу билгеләре ачыкланган очракта, административ хокук бозу эшләрен кузгата һәм билгеләнгән тәртиптә аларның каралуын тәэмин итә.

Контрольлек чарасы барышында контрольлек чарасын уздыру объекты булып торган хуҗалык яки башка эшчәнлекнең законнарның таләпләрне бозуга бәйле булуы ачыкланса, аларны ачыклау, булдырмый калу һәм чикләү мәсьәләләре ТР ЭТРМ вәкаләтләренә карамаса, ТР ЭТРМ Россия Федерациясенең яки Татарстан Республикасының тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына (Татарстан Республикасы буенча табигатьтән файдалану идарәсе, Росприроднадзорның ТР буенча идарәсе, Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең Идел буе идарәсе (Ростехнадзор), Россельхознадзорның Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Су ресурслары федераль агентлыгының Түбән Идел бассейны су идарәсенең ТР буенча су ресурслары бүлеге, Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Баш ветеринария идарәсе, Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы, Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы, Татарстан Республикасы Прокуратурасы, Казан районара табигать саклау прокуратурасы, «Татарстан Республикасы Гидрометеорология һәм әйләнә-тирә мохитне мониторинглау идарәсе» федераль дәүләт бюджет учреждениесе) мондый бозулар турында мәгълүмат җиткерергә тиеш.

Тикшерү актының бер нөсхәсен (кушымталары белән бергә) җаваплы башкаручы эшкә куша, икенчесен (кушымталары белән бергә) юридик зат җитәкчесенә, юридик затның башка вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә танышып чыгу турында яисә тикшерү акты белән танышудан баш тарту турында имзалатып тапшыра.

Юридик затның җитәкчесе, бүтән вазыйфаи заты яисә вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле булмаган очракта, шулай ук тикшерелә торган затның тикшерү акты белән танышып чыгуы турында яисә танышып чыгудан баш тарту турындагы имза куясы килмәсә, акт кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә, кулга алу турындагы белдерүнамә ТР ЭТРМ эшендә саклана торган тикшерү акты нөсхәсенә теркәлә. Тикшерелә торган затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) яки муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүгә ризалыгы булган очракта, тикшерү акты юридик затның җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яисә вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрелергә мөмкин. Шул ук вакытта бу актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган, тикшерелә торган затка әлеге документның алынуын раслауны тәэмин итә торган ысул белән электрон документ рәвешендә җибәрелгән акт тикшерелә торган зат тарафыннан алынган дип исәпләнә.

Үтәү вакыты:

- тикшерү актын төзү һәм тапшыру: тикшерү тәмамланганнан соң турыдан-туры;

- тикшерү актын заказлы хат итеп җибәрү: тикшерү чаралары тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә.

Эш нәтиҗәсе: ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты, кушымталары белән, берсе юридик затка тапшырылган (җибәрелгән), икенчесе шәхси эшкуар эшенә теркәп куелган.

5.1.8. Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерү җибәрә.

5.1.9. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы документар тикшерү үткәрү» административ процедураның үтәлеше ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон формада теркәлә.

5.2. «Юридик затка, шәхси эшкуарга күчмә планлы тикшерү уздыру» административ процедурасы.

5.2.1. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы күчмә тикшерүне уздыру» административ процедурасын башлау өчен тиешле юридик затны, шәхси эшкуарны ТР ЭТРМның еллык планына кертү нигез булып тора, шулай ук, әгәр документар тикшерү барышында түбәндәгеләр мөмкин булмаса да:

1) юридик затның, шәхси эшкуарның ТР ЭТРМ карамагында булган документларындагы белешмәләрнең тулы һәм төгәл булуына инану;

2) юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контрольлек буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

Лицензиатка карата планлы тикшерүне планлы тикшерүләр уздыруның еллык планына кертү әлеге Регламентның 2.4.1 пунктында күрсәтелгән нигезләрдә гамәлгә ашырыла.

5.2.2. Җаваплы башкаручыларны, экспертларны билгеләү, юридик затка, шәхси эшкуарга тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) әзерләү, тикшерү үткәрү турында юридик затка, шәхси эшкуарга хәбәр итү әлеге Регламентның 5.1.2-5.1.4 пунктларында каралган тәртиптә гамәлгә ашырыла.

5.2.3. Җаваплы башкаручылар, экспертлар, эксперт оешмалары вәкилләре юридик зат, шәхси эшкуар объектына килеп җитү белән тикшерүне түбәндәгечә башлыйлар:

- хезмәт таныклыгын күрсәтеп;

- юридик затны, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкилен күчмә тикшерүне билгеләү турында министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) белән мәҗбүри таныштырып;

- юридик затны, шәхси эшкуарны, аның вәкаләтле вәкиле затларын күчмә тикшерүне уздыручы затларның вәкаләтләр белән, шулай ук урынга барып тикшерүне уздыруның максатлары, бурычлары, нигезләре, тикшереп тору чараларының төрләре һәм күләмнәре, экспертлар составы, урынга барып

тикшерүгә җәлеп ителә торган эксперт оешмалары вәкилләре, аны үткәрү сроклары һәм шартлары белән зарури таныштырып.

Җаваплы башкаручы контрольлек буенча түбәндәге чараларны үткәрә:

юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең әлеге Регламентның 3 бүлегендә китерелгән зарури таләпләргә туры килү-килмәвен бәяли;

күчмә тикшерү актын рәсмиләштерә.

Планлы тикшерү барышында юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан зарури  таләпләр үтәлмәвен ачыклаган очракта, җаваплы башкаручы:

тикшерү актында ачыкланган бозуларның барлык очракларын да терки;

бетерү вакытларын күрсәтеп, ачыкланган бозуларны бетерү турында һәм кешеләрнең гомеренә, сәламәтлегенә зыян салынуны, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарихи һәм мәдәни ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә, физик һәм юридик затларның мөлкәтенә, дәүләти яисә муниципаль мөлкәткә булган зыянны туктату, табигый һәм техноген холыклы гадәттән тыш хәлләр барлыкка килүен кисәтү буенча чаралар, шулай ук федераль законнарда каралган башка чараларны уздыру турында күрсәтмә (күрсәтмә формасы әлеге Регламентка 2 нче кушымтада китерелгән) әзерли һәм юридик затка, шәхси эшкуарга тапшыра. Күрсәтмә тикшерү актына кушымта булып тора (һәр бозу очрагына аерым күрсәтмә);

юридик затның, шәхси эшкуарның зарури таләпләрне бозган өчен җаваплылык йөкләнгән хезмәткәрләреннән аңлатмалар сората;

калдыклар белән эш итү өлкәсендә (радиоактив калдыклардан тыш) законнар бозылуга юл куйган затларны билгеләнгән тәртиптә административ җаваплылыкка тарта законнар.

ТР ЭТРМ махсуслаштырылган аналитик контрольлек инспекцияләре белгечләре түбәндәге чараларны уздыра:

- алга таба лаборатор анализ һәм беркетмәләр рәвешендә анализ нәтиҗәләрен бирү өчен тикшерү объектларын сайлап алу;

- үрнәкләрне сайлап алганда кирәкле параметрларны үлчи;

- үрнәкләрне алу актын рәсмиләштерә.

Тикшерү объектларыннан тикшерү үрнәкләрен алу чараларын җаваплы башкаручы координацияли.

Үтәү вакыты: юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты – егерме эш көненнән дә артмый.

5.2.4. Тикшерү актын төзү шушы Регламентның 5.1.7 пунктында күрсәтелгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Тикшерү актына түбәндәгеләр теркәлә:

- продукция үрнәкләрен сайлап алу, тикшерү пробалары беркетмәләре;

- үткәрелгән тикшерүләрнең, сынауларның һәм экспертизаларның беркетмәләре яисә бәяләмәләре;

- тикшерү нәтиҗәләренә бәйле башка документлар яисә аларның күчермәләре.

Әгәр тикшерү актын төзү өчен үткәрелгән тикшеренүләрнең, сынауларның, махсус тикшерүләрнең, экспертизаларның бәяләмәсен алу кирәк

булса, тикшерү акты контрольлек чараларын тәмамлаганнан соң өч эш көненнән артып китмәгән чорда төзелә һәм юридик зат җитәкчесенә, бүтән вазыйфаи затына яки вәкаләтле вәкиленә, шәхси эшкуарга, аның вәкаләтле вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла яисә кулга тапшыру турында белдерүле заказлы почта юлламасы итеп җибәрелә һәм (яисә) шушы актны төзегән затның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә (тикшерелүче затның дәүләт контроле (күзәтчелеге) яки муниципаль контроль кысаларында электрон рәвештә хезмәттәшлек итүне гамәлгә ашыруга ризалыгы булган очракта), күрсәтелгән документның алынуын тәэмин итүче ысул белән җиткерелә. Бу вакытта кулга тапшыру турыда хәбәрләмә һәм (яисә) күрсәтелгән документның алынуына бүтәнчә дәлилләмә тикшерү актының ТР ЭТРМ саклана торган эштәге нөсхәсенә кушып куела.

Уздырылган тикшерү турында тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) язу терки, анда уздырылган тикшерү турындагы язуда дәүләт контроле (күзәтчелеге) органының аталышы, тикшерүне уздыра башлау һәм тәмамлау даталары, аны уздыру вакыты, тикшерүнең хокукый нигезләре, максатлары, бурычлары һәм предметы турында белешмәләр була, шулай ук тикшерүне уздыручы вазыйфаи затның яки вазыйфаи затларның фамилияләре, исемнәре, аталарының исемнәре һәм вазыйфалары, аның яки аларның имзалары күрсәтелә.

5.2.5. Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы тикшерү уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага белдерү җибәрә.

5.2.6. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы күчмә тикшерү үткәрү» административ процедураның үтәлеше ТР ЭТРМның рәсми сайтында электрон формада теркәлә.

5.3. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасы

5.3.1. Әлеге Регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар «Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедурасын башлау өчен нигез булып тора.

«Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү уздыру» административ процедурасы гамәлләрнең түбәндәге тәртибенә ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла:

планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү турында карар кабул итү;

планнан тыш документар тикшерү уздыру турында министр (министр урынбасары) боерыгын (күрсәтмәләрен) рәсмиләштерү;

планнан тыш документар тикшерү үткәрү;

планнан тыш документар тикшерү нәтиҗәләрен рәсмиләштерү.

5.3.2. Министр (министр урынбасары) әлеге Регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләр туганда ТР ЭТРМ тиешле структур бүлекчәсе җитәкчелегенә планнан тыш документар тикшерү оештыру һәм үткәрү турында йөкләмә бирә.

ТР ЭТБМның структур бүлекчәсе башлыгы:

юридик затка, шәхси эшкуарга карата тикшерү уздыру өчен җаваплы башкаручыны билгели;

тикшерү уздырыла торган юридик затлар, шәхси эшкуарлар белән гражданлык-хокукый һәм хезмәт мөнәсәбәтләрендә тормаган һәм тикшерелә торган затларның аффилирланган затлары булмаган экспертларны, эксперт оешмаларын тикшерүгә җәлеп итә.

Үтәү вакыты: планнан тыш тикшерү үткәрү өчен нигезләр барлыкка килгән көннән соң бер эш көне эчендә.

Эшнең нәтиҗәсе: юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерүне гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән вазыйфаи затлар исемлеге һәм җаваплы башкаручы.

5.3.3. Министрның (министр урынбасарының) юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерыгын (күрсәтмәсен) әзерләү әлеге Регламентның 5.1.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үтәлү вакыты: юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручы билгеләнгән көнне.

Эш нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган тикшерү үткәрү турында боерык (күрсәтмә).

5.3.4. Юридик зат, шәхси эшкуар документларындагы белешмәләрне бәяләү, юридик зат, шәхси эшкуар адресына хат (мотивлаштырылган гариза) әзерләү, юридик зат, шәхси эшкуар аңлатмаларын карау буенча җаваплы башкаручының гамәлләре әлеге Регламентның 5.1.5, 5.1.6 пунктлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.3.5. Тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.1.7 пунктында билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

Элегрәк ачыкланган закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшергәндә, ТР ЭТРМ законлы күрсәтмәсен вакытында үтәмәү, шулай ук Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.5 (1 өлеш), 19.6 статьяларында каралган административ хокук бозуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрү административ хокук бозулар турында эш кузгату өчен нигез булып тора.

5.3.6. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш документар тикшерү үткәрү» административ процедураның үтәлеше ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон формада теркәлә.

5.4. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү уздыру» административ процедурасы

5.4.1. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү» административ процедурасын башлап җибәрү өчен әлеге Регламентның 2.4.2 пунктында күрсәтелгән очраклар, шулай ук документар тикшерү вакытында түбәндәгеләр мөмкин булмаса да, нигез булып тора:

1) ТР ЭТРМ карамагында булган юридик зат, шәхси эшкуар документларындагы белешмәләрнең тулылыгы һәм дөреслеге белән танышырга;

2) юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлегенең зарури таләпләргә туры килүен контрольлек буенча тиешле чараларны үткәрмичә бәяләү.

5.4.2. Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү үткәрү өчен җаваплы башкаручыны, экспертларны билгеләү әлеге Регламентның 5.1.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5.4.3. Министрның (министр урынбасарының) юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү үткәрү турында боерыгын (күрсәтмәсен) әзерләү әлеге Регламентның 5.1.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Үтәү вакыты: юридик затны, шәхси эшкуарны тикшерү өчен җаваплы башкаручылар билгеләнгән көнне.

Эш нәтиҗәсе: министр (министр урынбасары) тарафыннан имзаланган тикшерү үткәрү турында боерык (күрсәтмә).

5.4.4. Планнан тыш күчмә тикшерүне үткәрү өчен әлеге Регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасындагы «а», «б» пунктчаларында күрсәтелгән нигезләр нигез булып торса, җаваплы башкаручы:

юридик затка, шәхси эшкуарга карата планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турында юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлекне гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына гариза әзерли һәм аны Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының төбәк дәүләт экология күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентының 5 нче кушымтасында китерелгән форма буенча министрдан (министр урынбасарыннан) имзалаттыра;

юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү уздыруны килештерү турындагы гаризаны юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлекне гамәлгә ашыру урыны буенча прокуратура органына турыдан-туры, кулга тапшыру турында белдерү белән заказлы хат итеп почта аша яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында җибәрә. Бу гаризага планнан тыш тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) күчермәсе һәм аны үткәрүгә нигез булган белешмәләре булган документлар теркәлә.

Үтәү вакыты: министр (министр урынбасары) тарафыннан боерыкка (күрсәтмәгә) кул куелган көнне юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш тикшерү үткәрү.

Эш нәтиҗәсе: прокуратура органына җибәрелгән планнан тыш тикшерү үткәрүне килештерү турында гариза.

Әгәр планнан тыш күчмә тикшерү уздыру өчен гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә зыян китерү, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә зыян китерү, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр килеп

чыгу, муниципаль хокукый актларда билгеләнгән мәҗбүри таләпләр һәм таләпләр бозылу нигез булса, кичектергесез чаралар күрү зарурлыгына бәйле рәвештә мондый хокук бозулар башкарылган вакытта җаваплы башкаручы, прокуратура органнарына тикшерү үткәрү башлануга кимендә егерме сәгать кала мөмкин булган белешмәләр булган документларны җибәрү юлы белән контрольдә тоту чараларын үткәрү турында хәбәр итеп, ашыгыч рәвештә читкә китеп тикшерүне үткәрүгә керешергә хокуклы.

5.4.5. Планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү турында (әлеге Регламентның 2.4.2 пунктының 2 пунктчасында күрсәтелгән планнан тыш күчмә тикшерүдән тыш) юридик затка, шәхси эшкуарга эшкуарга аны үткәрү башланганчы егерме дүрт сәгатьтән дә соңга калмыйча җаваплы башкаручыга хәбәр ителә.

Юридик зат, шәхси эшкуар эшчәнлеге нәтиҗәсендә гражданнарның гомеренә, сәламәтлегенә, хайваннарга, үсемлекләргә, әйләнә-тирә мохиткә, Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларына (тарих һәм мәдәният ядкәрләренә), дәүләт иминлегенә зыян китерелсә яисә зыян салса, шулай ук табигый һәм техноген рәвештәге гадәттән тыш хәлләр килеп чыгарга мөмкин, юридик затларга, шәхси эшкуарларга планнан тыш тикшерү үткәрү башлануы турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

Үзкөйләнешле оешма әгъзаларына планнан тыш тикшерү үткәрелгән очракта, җаваплы башкаручы, планнан тыш күчмә тикшерү үткәргәндә аның вәкиленең катнашу мөмкинлеген тәэмин итү максатларында, планнан тыш тикшерү үткәрү турында үзкөйләнешле оешмага хәбәр җибәрә.

5.4.6. Планнан тыш күчмә тикшерүне уздыру әлеге Регламентның 5.2.3 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

Элегрәк ачыкланган закон бозуларны бетерү турындагы күрсәтмәләрнең үтәлешен тикшергәндә, ТР ЭТРМ законлы күрсәтмәсен вакытында үтәмәү, шулай ук Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 19.5, 19.6 статьяларында каралган административ хокук бозуга китергән сәбәпләрне һәм шартларны бетерү буенча чаралар күрү административ хокук бозулар турында эш кузгату өчен нигез булып тора.

5.4.7. Тикшерү актын төзү әлеге Регламентның 5.2.4 пункты нигезендә башкарыла.

Әгәр планнан тыш тикшерү прокуратура органы белән килештереп башкарылса, тикшерү актының күчермәсе тикшерү акты төзелгән көннән алып биш эш көне эчендә прокуратура органына җибәрелә.

5.4.8. Үзкөйләнешле оешма әгъзаларының зарури таләпләрне бозуы ачыкланган очракта, җаваплы башкаручы планнан тыш күчмә тикшерү уздыру тәмамланган көннән соң биш эш көне эчендә ачыкланган бозулар турында үзкөйләнешле оешмага хәбәр итә.

5.4.9. «Юридик затка, шәхси эшкуарга планнан тыш күчмә тикшерү үткәрү» административ процедураның үтәлеше ТР ЭТРМ рәсми сайтында электрон формада теркәлә.

6. Дәүләт функциясе үтәлешен контрольдә тоту тәртибе һәм формалары

6.1. ТР ЭТРМ вазыйфаи затлар тарафыннан аларның хезмәт вазыйфалары үтәлүен тикшереп тора, вазыйфаи затлар тарафыннан хезмәт вазыйфалары тиешенчә үтәлмәү очракларының исәбен алып бара, тиешле хезмәт тикшерүләрен үткәрә һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә мондый вазыйфаи затларга карата чаралар күрә.

6.2. Бу Регламент үтәлешен тикшереп тору министр тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.3. Әлеге Регламентка ярашлы рәвештә дәүләт күзәтчелеген үтәү чорлары, гамәлләрне башкару эзлеклелеге үтәлүгә, ТР ЭТРМ вазыйфаи затларының карарлар кабул итүенә агымдагы контрольлек министр урынбасары һәм ТР ЭТРМ вәкаләтле хезмәткәрләре тарафыннан гамәлгә ашырыла.

6.4. Дәүләт функциясе, әлеге контрольлекне гамәлгә ашыру тәртибе һәм эзлеклелеге үтәлүенә агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыруга вәкаләтле ТР ЭТРМ хезмәткәрләре исемлеге ТР ЭТРМ актларында билгеләнә. Агымдагы контрольлекне гамәлгә ашыруга ТР ЭТРМ хезмәткәрләренең вәкаләтләре ТР ЭТРМ структур бүлекчәләре турында нигезләмәләрдә, хезмәткәрләрнең вазыйфаи күрсәтмәләрендә билгеләнә.

6.5. Дәүләт функциясенең ТР ЭТРМ тарафыннан үтәлүенең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын тикшереп тору планлы һәм планнан тыш тикшерүләр уздыруны, тикшерелә торган затларның хокуклары бозылуны ачыклау һәм бетерүне, карарлар кабул итүне һәм мәнфәгатьле затларның ТР ЭТРМ вазыйфаи затлары гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрне үз эченә ала торган мөрәҗәгатьләренә җаваплар әзерләүне үз эченә ала.

Тикшерүләр министр (министр урынбасары) боерыгы (күрсәтмәсе) нигезендә уздырыла. Тикшерү нәтиҗәләре акт рәвешендә рәсмиләштерелә, анда дәүләт функциясен үтәгәндә җитешсезлекләрнең булмавы яки ачыкланган җитешсезлекләр һәм аларны бетерү буенча тәкъдимнәр теркәлә.

6.6. Дәүләт функциясен үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планлы тикшерүләр агымдагы елга ТР ЭТРМ еллык эш планына ярашлы рәвештә уздырыла. Планлы тикшерүләр күрсәтелгән планга дәүләт функциясен үтәүгә компетентлы булган министр урынбасары тарафыннан кертелә.

6.7. Дәүләт функциясен үтәүнең тулы һәм сыйфатлы булу-булмавын планнан тыш тикшерүләр дәүләт функциясен үтәү барышында ТР ЭТРМ вазыйфаи затлар тарафыннан кабул ителгән яисә гамәлгә ашырылган карарларга яки гамәлләргә (гамәл кылмауларына) гражданнарның шикаятьләре нигезендә оештырыла һәм үткәрелә.

6.8. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә, дәүләт функциясен башкарганда Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан җитешсезлекләр җибәрелүе ачыкланган очракта, гаепле затлар Россия Федерациясе законнары нигезендә җаваплылыкка тартыла һәм ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрелә.

6.9. Калдыклар белән эш итү өлкәсендә иҗтимагый контроль (иҗтимагый экология контроле) иминлекле әйләнә-тирәлеккә һәркемнең хокукын тормышка ашыру һәм әйләнә-тирә мохит өлкәсендәге законнар бозылуны булдырмый калу максатларында гамәлгә ашырыла.

Калдыклар белән эш итү өлкәсендә иҗтимагый контроль (иҗтимагый экология контроле) иҗтимагый берләшмәләр һәм коммерциясез бүтән оешмалар тарафыннан аларның уставлары нигезендә, шулай ук гражданнар тарафыннан законнар нигезендә гамәлгә ашырыла.

Россия Федерациясе дәүләт хакимияте органнарына, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына тапшырылган калдыклар белән эш итү (иҗтимагый экологик контроль) өлкәсендәге иҗтимагый контроль нәтиҗәләре законнарда билгеләнгән тәртиптә мәҗбүри каралырга тиеш.

7. Дәүләт функциясен үтәүче башкарма органның, шулай ук аның вазыйфаи затларының карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

7.1. Юридик затның җитәкчесе, башка вазыйфаи заты яки вәкаләтле вәкиле, шәхси эшкуар, аның вәкаләтле вәкиле, башка мәнфәгатьле затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүчеләр) дәүләт функциясен үтәү барышында ТР ЭТРМ, андагы вазыйфаи затларның тикшерү уздырганда юридик затның, шәхси эшкуарның хокуклары бозылуга китереп чыгарган гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарларына Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерү хокукына ия.

7.2. ТР ЭТРМ, аның территориаль идарәләре, андагы вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү предметы булып ТР ЭТРМ вазыйфаи затларның дәүләт функциясен үтәү барышында кабул иткән яисә гамәлгә ашырган карарлары яисә гамәлләре (гамәл кылмавы) тора.

7.3. Министрлыкка яисә вазыйфаи затка аларның компетенциясе нигезендә кергән шикаять мәҗбүри каралырга тиеш.

Судка кадәр (судтан тыш) шикаятьне карап тикшерүдән баш тарту яисә карап тикшерүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

7.4. Шикаятькә җавап яисә шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап түбәндәге очракларда бирелми:

- әгәр язмача шикаятьтә шикаятьне юллаган мөрәҗәгать итүченең фамилиясе (юридик затның атамасы, шәхси эшкуарның фамилиясе) яки җавап җибәрелергә тиешле почта адресы күрсәтелмәсә, шикаятькә җавап бирелми (әгәр күрсәтелгән шикаятьтә әзерләнә, кылына яки кылынган хокукка каршы гамәл турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә туры китереп тиешле дәүләт органына җибәрелергә тиеш);

- әгәр язмача шикаятьтә цензурасыз яисә мыскыллы гыйбарәләр, ТР ЭТРМ вазыйфаи затының, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә

һәм мөлкәтенә янаулар булса (мондый шикаятькә ТР ЭТРМ вазыйфаи заты хокуктан явызларча файдалануның ярамавы турында шикаятьне җибәрүчегә хәбәр итәргә хокуклы);

- әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләренә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе һәм почта адресы укылышлы булса;

әгәр сорауда мөрәҗәгать итүченең элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә аңа берничә тапкыр язма җаваплар бирелгән һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яки шартлар китерелми торган соравы булса (элек җибәрелгән шикаять бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә бер үк вазыйфаи затка (шикаять җибәргән мөрәҗәгать итүче, шикаятьне туктатырга карар турында хәбәр ителә), күрсәтелгән шикаять һәм элек җибәрелгән шикаятьләр бер үк дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булса);

- әгәр шикаятьтә куелган мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне юллаган мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

Суд карарына шикаять белдерелгән шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарына шикаять белдерү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

7.5. ТР ЭТРМ гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү процедурасын башлап җибәрү өчен нигез булып, Министрлыкның, аның вазыйфаи затларының гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять бирү процедурасын башлап җибәрү өчен ТР ЭТРМ шәхсән мөрәҗәгать итүчедән (мөрәҗәгать итүченең вәкаләтле вәкиленнән), йә почта аша җибәрү рәвешендә, яисә «Интернет» челтәреннән, шул исәптән ТР ЭТРМ рәсми сайтыннан яки Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталыннан файдаланып, электрон документ килү тора.

7.6. Юридик затлар, шәхси эшкуарлар шикаятьне нигезләү һәм карап тикшерү өчен кирәкле булган мәгълүматларны һәм документларны алырга хокуклы. Мондый төр мәгълүматларны һәм документларны алу өчен юридик затлар, шәхси эшкуарлар ТР ЭТРМ адресына язмача рәвештә тиешле гарызнамәне язмача яисә электрон рәвештә җибәрергә тиеш. Министр (министр урынбасары), җаваплы башкаручылар соратып алына торган белешмәләрне һәм документларны гаризаны теркәгәннән соң 30 көн эчендә тапшырырга тиеш.

7.7. ТР ЭТРМ вазыйфаи затларның гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять министрга җибәрелергә мөмкин. ТР ЭТРМ һәм министрның гамәлләренә (гамәл кылмавына) һәм карарларына шикаять Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына җибәрелергә мөмкин.

7.8. Компетенцияләренә ярашлы рәвештә, ТР ЭТРМ яисә ТР ЭТРМ вазыйфаи затына килгән шикаять аны теркәүгә алган көннән соң 30 календарь көненнән артмаган чорда карала.

Искәрмәле очракларда, шулай ук әлеге пунккта күрсәтелгән гаризаны җибәргән очракта да, вазыйфаи зат яисә моңа вәкаләте булган зат шикаятьне карау вакытын, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә аны карау вакытын озынайту турында хәбәр итеп, иң күбе 30 календарь көнгә озынайтырга хокуклы.

7.9. Судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү нәтиҗәләре булып түбәндәгеләр тора:

1) дәүләт функциясен үтәү барышындагы гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырылучы) карарларга судка кадәр (судтан тыш) белдерелгән шикаятьне канәгатьләндерү, ә атап әйткәндә:

- хезмәт тикшерүе барышында җаваплы башкаручының (җаваплы башкаручыларның) хезмәт вазыйфаларын тиешенчә үтәмәү фактлары ачыкланган очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә аларга карата чаралар күрү;

- хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылган юридик затларга, шәхси эшкуарларга Россия Федерациясе законнары таләпләрен бозуда гаепле җаваплы башкаручыларга карата кабул ителгән чаралар турында мондый чаралар кабул ителгән көннән соң ун көн эчендә язмача рәвештә хәбәр итү;

2) юридик затларга, шәхси эшкуарларга, мондый карарны дәлилле рәвештә нигезләп, язмача рәвештә хәбәр итү юлы белән, дәүләт күзәтчелеген гамәлгә ашыру барышында гамәлләргә (гамәл кылмауларга) һәм кабул ителгән (гамәлгә ашырыла торган) карарларга судка кадәр (судтан тыш) белдерелгән дәгъваны канәгатьләндермәү.

7.10. ТР ЭТРМ килгән шикаятькә җавап мөрәҗәгать итүчегә әлеге Регламентның 7.9 п. каралган чаралар күрелгән көннән соң 10 көн эчендә җибәрелә.

ТР ЭТРМ яисә вазыйфаи затка электрон документ рәвешендә килгән мөрәҗәгатькә (шикаятькә) җавап электрон документ рәвешендә шикаятьтә күрсәтелгән электрон почта адресы буенча яки язмача рәвештә шикаятьтә күрсәтелгән почта адресы буенча җибәрелә.

**Төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча**

**Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы административ регламентына 1 нче кушымта**

**(Бер төр рәвеше)**

Административ хокук бозу турында беркетмә (юридик затка карата) (форма)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ

______________________________________________________________________________.

N ______________________

(теркәүгә алу кенәгәсе буенча)

БЕРКЕТМӘ N __________________

административ хокук бозу турында

«___»_____________ 201__ ел. _______________________________

(беркетмә төзү датасы) (беркетмә төзү урыны)

Мин, табигатьне саклау буенча ТР дәүләт инспекторы ________________________

______________________________________________________________________________.

(беркетмә төзегән затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 6, 66 ст., 2001 елның 30 декабрендәге 195-ФЗ номерлы Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы) 28.2 ст., 28.3 ст. 1 өлешенә таянып, түбәндәгегә карата беркетмә төзедем

______________________________________________________________________________.

(юридик затның оешу-хокук рәвеше һәм аталышы)

______________________________________________________________________________.

(юридик адресы, телефон)

_____________________________________________________________________________.

_____________________________________________________________________________.

Төп дәүләт теркәлү номеры (ОГРН) | | | | | | | | | | | | | | |

Юридик затның реквизитлары ИНН/КПП | | | | | | | | | | | / | | | | | | | | | |

и/с | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | кайда _________________________

(Банк исеме)

кор/с | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

БИК | | | | | | | | | | ОКПО | | | | | | | | | ОКВЭД | | | | | ОКОНХ | | | | | |

түбәндәгеләр катнашында: ____________________________________________________ (юридик затның законлы вәкиле вәкаләтләрен раслаучы документ,

_____________________________________________________________________________.

юридик затның законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме)

ул административ хокук бозды, әлеге хәл түбәндәгеләрнең бозылуында чагыла ________________________________________________________________

(әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендәге федераль законнарның, нормативларның, норматив документларның тулысынча аталышы күрсәтелә)

_____________________________________________________________________________.

_______________________________________________________________________________

_.

аның өчен Административ хокук бозулар турында РФ кодексының ________ ст. нигезендә җаваплылык каралган, ә атап әйткәндә:

«___» ___________ 201 __ ел. ___ сәг. ____ мин. ___________ торак пунктында

_______________________________________________________________________________

_.

Биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне эксплуатацияләгәндә ___________________________

(хокук бозу вакыйгасы, хокук бозуларны санап чыгу

_______________________________________________________________________________

_.

табигать саклау законнары таләпләре, мәйданы, күләме)

_______________________________________________________________________________

_.

_______________________________________________________________________________

_.

Әлеге беркетмә үзенә карата административ хокук турында эш алып барыла торган зат (юридик затның законлы вәкиленең ФИА) ___________________________ катнашында төзелде, аңа Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 25.1, 25.4 статьяларында каралган хокуклары һәм бурычлары турында аңлатылды. Рус телен белəм, тәрҗемәчегә мохтаҗ түгел (административ җаваплылыкка тартыла торган зат эш материаллары белән танышырга, аңлатмалар бирергә, дәлилләр китерергә, үтенеч язулары һәм каршы чыгуларны белдерергә; беркетмә төзүгә вәкаләтле затның процессуаль гамәлләренә шикаять белерергә; эшне караганда яклаучының юридик зат ярдәменнән файдаланырга, шулай ук әлеге Кодекска ярашлы рәвештә башка процессуаль хокуклардан файдаланырга хокуклы).

Таныштым: _________________________________________________________________

(юридик затның законлы вәкиленең имзасы, тулы имзасы)

Юридик затның законлы вәкиленең аңлатмалары һәм искәрмәләре: ______

_______________________________________________________________________________

_.

(беркетмә эчтәлеге буенча аңлатмалар һәм искәрмәләр, кирәк булганда,

_______________________________________________________________________________

_.

аңа аерым биттә теркәп куела)

_____________________________________________________________________________
_.

_____________________________________________________________________________
_.

__________________________________________________

(юридик затның законлы вәкиленең имзасы, тулы имзасы)

Шаһитлар: 1. (Ф.И.А.)
________________________________________________

(яшәү урыны адресы, телефон)

2. (Ф.И.А.)
___________________________________________________________

(яшәү урыны адресы, телефон)

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 25.6 статьясында каралган хокуклар һәм бурычлар турында миңа аңлатылды: 1. ________________________ 2. ____________________________

(имза, тулы имза) (имза, тулы имза)

Беркетмәгә кушымта итеп бирелә _______________________________________________

(беркетмәгә теркәлә торган документларны күрсәтергә)

_____________________________________________________________________________
_.

_____________________________________________________________________________
_.

Сез административ хокук бозуларны карау өчен чакырыласыз

______________ адресы: ________________ урам _______________ йорт ______

______ каб. ______ ______ сәг. ______ мин. «___»______________ 201__ ел.

Чакырылган затның имзасы: ________________________________________

(юридик затның законлы вәкиленең имзасы, тулы имзасы)

Беркетмә төзегән затның имзасы: ______________________________

(имза, тулы имза)

Беркетмә күчермәсен алдым ______________________________________________

(үзенә карата административ хокук бозу турында эш алып

барыла торган юридик зат вәкиленең имзасы, тулы имзасы)
«___»__________ 201__ ел.

**(Бер төр рәвеше)**

Административ хокук бозу турында беркетмә (вазыйфаи затка карата) (рәвеше)

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЭКОЛОГИЯ ҺӘМ ТАБИГАТЬ РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ

__________________________________________________________________________.

N ____________________
(теркәүгә алу кенәгәсе буенча)

БЕРКЕТМӘ N __________
административ хокук бозу турында

«___»______________ 201_ _ ел. ______________________
(беркетмәне төзү датасы) (төзү урыны)

Мин, табигатьне саклау буенча ТР дәүләт инспекторы _______________________

__________________________________________________________________________.

(беркетмә төзегән затның вазыйфасы, фамилиясе һәм инициаллары)

«Әйләнә-тирә мохитне саклау турында» 2002 елның 10 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы федераль законның 6, 66 ст., 2001 елның 30 декабрендәге 195-ФЗ номерлы Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының (алга таба – Административ хокук бозулар турында РФ кодексы) 28.2 ст., 28.3 ст. 1 өлешенә таянып, түбәндәгегә карата беркетмә төзедем

__________________________________________________________________________.

(физик, вазыйфаи зат, юридик зат төземәгән эшкуар)
(ПБОЮЛ)

┌─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┬─┐
│ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │ │
└─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┴─┘

Фамилия, исем, ата исеме

1. Туган көне һәм урыны ____________________________________________________

2. Эш урыны, вазыйфасы

____________________________________________________________________________.

(предприятие, учреждение атамасы, адресы, билгеләнү турында боерык)

3. Яшәү урыны һәм телефон ________________________________________________

4. Шәхси эшкуар өчен: ИНН ________________________________

5. Теркәлү урыны һәм телефон _______________________________________________

6. Шәхесне раслаучы документ _______________________________________

(сериясе, номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

ул административ хокук бозды, әлеге хәл түбәндәгеләрнең бозылуында чагыла ____________________________________________________________

(федераль законнарның, нормативларның тулы исеме күрсәтелә,

____________________________________________________________________________.

әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә норматив документлар)

____________________________________________________________________________.

аның өчен Административ хокук бозулар турында РФ кодексының _________ ст. нигезендә җаваплылык каралган, ә атап әйткәндә:

«___» ____________ 201 __ ел. ___ сәг. _____ мин. ____________ торак пунктында

____________________________________________

биналарны, корылмаларны, төзелмәләрне эксплуатацияләгәндә _______________________________

(вазыйфаи затлар өчен)

____________________________________________________________________________.

(юридик затның атамасы, урнашкан урыны)

адресы:

____________________________________________________________________________

(физик затлар өчен) (административ хокук бозу урыны адресы)

бозган:

____________________________________________________________________________

_.

(хокук бозу вакыйгасы, хокук бозуларны санап чыгу

_______________________________________________________________________________

_.

табигать саклау законнары, мәйданы, күләме

_______________________________________________________________________________

_.

_______________________________________________________________________________

_.

Әлеге беркетмә үзенә карата административ хокук турында эш алып барыла торган зат (ФИА) _________________________ катнашында төзелде, аңа Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 25.1, 25.4 статьяларында каралган хокуклары һәм бурычлары турында аңлатылды. Рус телен беләм, тәрҗемәчегә мохтаҗ түгел (административ җаваплылыкка тартыла торган зат эш материаллары белән танышырга, аңлатмалар бирергә, дәлилләр китерергә, үтенеч язулары һәм каршы чыгуларны белдерергә; беркетмә төзүгә вәкаләтле затның процессуаль гамәлләренә шикаять белерергә; эшне караганда яклаучының юридик зат ярдәменнән файдаланырга, шулай ук әлеге Кодекска ярашлы рәвештә башка процессуаль хокуклардан файдаланырга хокуклы).

Таныштым:

____________________________________________________________

(имза, тулы имза)

Үзенә карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган затның (физик затның законлы вәкиленең) аңлатмалары һәм кисәтүләре _______________________________________________________

_______________________________________________________________________________

_.

_______________________________________________________________________________

_.

______________________________

(имза, тулы имза)

Шаһитлар: 1. (Ф.И.А.)

_________________________________________________

(яшәгән урын адресы)

2. (Ф.И.А.)

____________________________________________________________

(яшәгән урын адресы)

Административ хокук бозулар турында РФ кодексының 25.6 статьясында каралган хокуклар һәм бурычлар миңа аңлатылды: 1.

_____________________________ 2. ____________________________
(имза, тулы имза) (имза, тулы имза)

Беркетмәгә кушымта итеп бирелә ____________________________________________________
(беркетмәгә теркәлә торган документларны күрсәтергә)

____________________________________________________________________________
_.

____________________________________________________________________________
_.

Сез административ хокук бозу турындагы эшне карап тикшерү өчен чакырыласыз ___ сәгатькә, «___»______ 201__ ел., адресы: ______________________

шәһәр ________________________, урам ________________, йорт ____, каб. ____

Чакырылган затның имзасы:____________________________________

Беркетмә төзегән затның имзасы: __________________________________
(имза, тулы имза)

Беркетмә күчермәсен алдым ____________________________________________________
(үзенә карата административ хокук бозу турында эш алып барыла торган затның имзасы, тулы имзасы)

«___»________________ 201_ ел.

**Төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы административ регламентына 2 нче кушымта**

**(Бер төр рәвеше)**

Ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ, Татарстан МИНИСТЕРСТВО ЭКОЛОГИИ
ЭКОЛОГИЯҺӘМ ТАБИГАТЬ Республикасы И ПРИРОДНЫХ РЕСУРСОВ
РЕСУРСЛАРЫ МИНИСТРЛЫГЫ Гербы РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

(дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы яисә аның территориаль органы атамасы)

_____________________________________________________________________________.

_____________________________________________________________________________.

Почта адресы: (дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы); тел.
(дәүләт контроле (күзәтчелеге) органы исеме)
________________________ «___»___________ 20__ ел.
(актны төзү урыны) (актны төзү датасы)
_______________________
(акт төзү вакыты)

**КҮРСӘТМӘ N ________**
**ТАБИГАТЬ САКЛАУ ЗАКОННАРЫН БОЗУЛАРНЫ БЕТЕРҮ ТУРЫНДА**

«___»________ 20 ел. ___________________ шәһ.

20___ елның __________ № _____ Россия Федерациясенең табигать саклау законнары таләпләрен үтәүне тикшерү акты нигезендә, мин, табигатьне саклау буенча ТР дәүләт инспекторы

_____________________________________________________________________________.

(ТР ЭТРМ яки аның территориаль органы вазыйфаи затының Ф.И.А.,

_____________________________________________________________________________.

вазыйфасы, хезмәт таныклыгы номеры, кем тарафыннан һәм кайчан бирелгән)

КҮРСӘТМӘ БИРӘМ

_______________________________________________________________________________.

(күрсәтмә бирелә торган физик яисә юридик затның исеме)

| /с | Табигать саклау законнары бозылуның ачыкланган очраклары** | Ачыкланган бозуларны бетерү буенча күрсәтмәнең эчтәлеге* | Үтәү вакыты |
|---|---|---|---|
| | 2 | 3 | 4 |
| | | | |
| | | | |
| | | | |

* Үзенә карата тикшерү үткәрелгән зат тарафыннан башкарылырга тиешле төгәл чаралар күрсәтелә.

** Күрсәтмә итеп бирелә торган вазыйфаны күздә тотучы норматив хокукый актка сылтамалар күрсәтелә.

Күрсәтмә законда билгеләнгән тәртиптә шикаять кылынырга мөмкин.

Шикаять кылу бу күрсәтмәне үтәүне туктата алмый.

Вазыйфаи затның имзасы:

_____________________________________________ _______________ ________________

(Ф.И.А.) (имза) (дата)

Күрсәтмә алынды

______________________________________________ ________________________________


(Шәхси эшкуарның яисә тикшерелә торган оешма җитәкчесенең (вәкаләтле вәкиленең) Ф.И.А.) (Шәхси эшкуарның яисә тикшерелә торган оешма җитәкчесенең (вәкаләтле вәкиленең) имзасы)


**Төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт**


**функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы административ регламентына 3 нче кушымта**

**(Бер төр рәвеше)**

**Дәүләт функциясен үтәү блогы-схемасы**




Тикшерү үткәрү турында министр (министр урынбасары) боерыгын әзерләү һәм имзалау, прокуратура органы белән килештерү (кирәк булган очракта)
Документар тикшерү
Күчмә тикшерү
Юридик затка, шәхси эшкуарга планлы тикшерү уздыру турында хәбәр итү – үткәрә башларга өч эш көне калгач, планнан тыш тикшерү турында – үткәрә башлар алдыннан 24 сәгать калгач
ТР ЭТРМ булган юридик затның, шәхси эшкуарның документларын карау
Законнарда билгеләнгән очракларда прокуратура органнары белән килештерү
Юридик зат, шәхси эшкуар адресына кирәкле документларны тапшыру турында хат (нигезле гарызнамә) җибәрү
ТР ЭТРМ вазыйфаи затлары гамәлләренә таләпләрне үтәп, урынга чыгып тикшерү үткәрү
Вазыйфаи зат (вазыйфаи затлар) тапшырылган документларны өйрәнә
Урынга чыгып тикшерү үткәрү турында карар кабул итү
Зурари таләпләрне бозу фактының булмавын билгеләү
Зарури таләпләрне бозу фактын билгеләү




**Төбәк дәүләт экология күзәтчелегенә тиешле хуҗалык һәм башка төрле эшчәнлек объектларында калдыклар белән эш итү өлкәсендә төбәк дәүләт күзәтчелеген, шулай ук җитештерү һәм куллану калдыкларын урнаштырган өчен түләүне контрольдә тотуны гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгы**

**административ регламентына 4 нче кушымта**

**(Бер төр рәвеше)**

**Юридик зат (шәхси эшкуар) объектында (объектларында) контрольлек буенча чаралар уздыру буенча җаваплы башкаручылар, СИАК белгечләре өчен план-йөкләмә**

Табигатьне саклау буенча ТР баш дәүләт инспекторының (Табигатьне саклау буенча ТР баш дәүләт инспекторы урынбасарының) ___________________________ юридик зат (шәхси эшкуар) объектында (объектларында) контрольлек буенча чаралар уздыру турында __________________ (дата) № ____ боерыгы (күрсәтмәсе) нигезендә

_____________________________________________________________________________.

_____________________________________________________________________________:

(юридик затның тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме, шул исәптән фирма атамасы, шәхси эшкуарның фамилиясе, исеме һәм (булган очракта) атасының исеме)

1. Тикшерү үткәрүгә вәкаләтле хезмәткәрләргә күрсәтелгән объектта (объектларда) түбәндәге чараларны үткәрергә кирәк:

| Күзәтчелек чарасы | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

2. Махсус аналитик контрольлек инспекциясенең тикшерү үткәрүгә вәкаләтле булган белгечләренә күрсәтелгән объектта (объектларда) түбәндәге чараларны үткәрергә кирәк:

| Күзәтчелек чарасы | Үтәү вакыты | Җаваплы башкаручы |
|---|---|---|
| | | |
| | | |

____________________________________________________________ __________________

(Баш җаваплы башкаручының ФИА, имзасы) (дата)